СИШӘМБЕ
16 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 13 (5813)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

„СЕДОВ“ БОЗВАТКЫЧЫ
Бадигинга, Трофимовка

„СЕДОВ“ БОЗВАТКЫЧЫ КОМАНДАСЫНА

Төньяк Боз океанында героик хәрәкәт кыенлыкларын уңышлы рәвештә җиңүегез уңае белән сезне һәм „Седов“ның бөтен экипажын котлыйбыз.

Москвага кайтуыгызны көтәбез.

Кайнар сәлам!

И. СТАЛИН. *В. МОЛОТОВ.*

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ
Папанинга, Белоусовка

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ КОМАНДАСЫНА

„Седов“ бозваткычын Гренландия диңгезе бозларыннан чыгару буенча заданиенең беренче өлешен гүзәл рәвештә үтәгән өчен безнең рәхмәтебезне кабул итегез.

Кайнар сәлам!

И. СТАЛИН. *В. МОЛОТОВ.*

Машиналар паркын отлично хәзерләү өчен

Тракторларга һәм башка авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны отлично сыйфат күрсәткечләре белән срогыннан элек тәгәлләүләре өчен Нөркәй, Тымытык һәм Теләче МТС лары республикабызның почет тактасына кертелделәр.

Бу МТС ларның шундый мактаулы урынны яулап алуга ирешүләре шатлыклы күренеш. Шуның белән бергә, ул—күп нәрсә турында сөйли торган факт. Аларның эш үрнәге безнең барлык МТС һәм МТМ нарыбызда да тракторларга һәм башка машиналарга ремонт ясауны югары сыйфат белән кыска срокта тәгәлләү өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр барлыгын һәм алардан файдалана белгәндә зур нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин икәнлеген раслый.

Без Нөркәй, Тымытык, Теләче МТС лары үрнәгендә социалистик авыл хуҗалыгы работниклары, МТС, МТМ эшчеләре арасында политик һәм производство активлыгының туктаусыз үсүен, Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәтенең көннән-көн киң колач ала баруын тагын бер кат күрәбез.

МТС һәм МТМ эшчеләре тракторларга ремонт ясауны яхшы сыйфатлы итеп срогында тәгәлләү өчен көрәшәләр. Моны башка МТС һәм МТМ нар мисалендә дә күрсәтергә мөмкин. Актаныш МТС ы ремонтчыларыннан Сәрвәрев, Ляпустин, Габдрахманов, Хәбиев һәм Сабиров иптәшләр көнлек нормаларны 175—200 процент үтәп, шулай ук почет тактасына керүгә ирештеләр. Биләр МТС ының иптәш Җиһаншин җитәкчелегендәге бригадасы да үзенә беркетелгән тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны тәгәлләп, почет тактасында мактаулы урын алды.

Әлмәт МТС ы коллективы Нөркәй МТС ы коллективы чакыруына кушылып алган йөкләмәсен конкрет эш белән ныгыта. Ремонтчылар арасында социалистик ярыш киң җәелдерелгән. 70 кешенең үзара индивидуаль ярыш договоры бар. Ярышып эшләү нәтиҗәсендә, Вәлиев һәм Туманов иптәшләрнең бригадалары тракторларга ремонт ясауны тәмамладылар инде. Коллектив барлык машиналарга ремонт ясауны 15 нче февральгә тәгәлләү өчен көрәшә. Мондый мисалларне күп китерергә була.

Республикада тракторларга ремонт ясау эше үткән елга караганда быел беркадәр алдарак бара. Мәсәлән, 1939 нчы елны 10 нчы гыйнварга план 27 процент үтәлгән булса, быел шушы числога 34,7 процент үтәлде. Ләкин бу темп канәгатьләнерлек түгел әле.

Үткән ел кайбер МТС ларда, мәсәлән, Әлки, Юдино, Кузайкино, Үзәк, Тат. Ходяш МТС ларында 15 нче апрельдә дә әле ремонт планының өчтән бер өлеше диярлек үтәлмәгән иде. Бу МТС ларның җитәкчеләре шушы хурлыклы факттан үзләре өчен тиешле нәтиҗәләрне ясарга һәм быел үткән елгы җитешсезлекләрне кабатламау өчен барлык чараларны күрергә тиешләр иде. Ләкин фактлар бөтенләй моның киресен күрсәтәләр. Әлки һәм Тат. Ходяш МТС ларында ремонт планы 1 нче гыйнварга 10,2—10,6 процент үтәлгән иде. Соңгы 10 көн эчендә үсеш бер процент та булмады.

Ни өчен ремонт эшенең темпы канәгатьләнерлек булудан ерак тора соң? Күп кенә МТС ларның директорлары, җир органнары җитәкчеләре быелгы ремонт кампаниясенең бик әһәмиятле үзенчәлеген аңлап җиткермәгәннәр. Быел, ремонт өчен кирәкле частьләрнең шактый өлешен МТС лар һәм МТМ нар үзләрендә хәзерләргә тиешләр. Димәк, теге яки бу МТС ның, МТМ ның уңышы, аның үзендә булган мөмкинлекләрдән ничек файдалануына, төзәтергә яраклы иске частьләрне яңартуны һәм яңа частьләр хәзерләүне ничек оештыруына бәйләнгән.

Хезмәтне дөрес оештыру ремонтның уңышлы тәгәлләнүе өчен хәл иткеч шартларның берсе. Ләкин кайбер урыннарда хезмәтне оештыруга бөтенләй игтибар бирмиләр. Мисаль өчен Балтач МТС ын (директоры иптәш Галиев) алу да җитә. Бу МТС та эшчеләргә нарядлар вактында бирелми. Һәрбер эшченең нык билгеләнгән эш урны юк. Кемнең эшкә кайчан килүе, кайчан китүе турында учет алып барылмый. Производство киңәшмәләре үткәрелми. Эшчеләр арасында социалистик ярыш договорлары төзелмәгән. Шушылардан соң МТС ның ремонт планын 10 нчы гыйнварга 20,8 процент кына үтәп, республикада иң артта баручы МТС лар рәтендә калуы очраклы түгел.

Шундый ук җитешсезлекләр Норлат МТС ында да дәвам итеп килә. Биредә ремонтчылар арасында хезмәт дисциплинасы бик йомшак.

Мондый җитешсезлекләргә юл кую ачыктан-ачык ремонт эшенен сузылуына юл кую дигән сүз. Һәрбер МТС, МТМ директоры, механик, җир органнары работниклары моны бер минутка да онытмаска, ремонтка тоткарлык ясый торган барлык кимчелекләрне ашыгыч бетерү өчен кискен чаралар күрергә тиешләр.

Ремонтта төп бурычларның берсе—сыйфат өчен көрәш. Ремонтның югары сыйфат белән башкарылуын, барлык детальләрнең техник таләпләргә тулысынча җавап бирерлек итеп хәзерләнүен тәэмин итү һәрбер тракторчының, механикның мактаулы бурычы.

МТС, МТМ директорлары, җир органнары работниклары кешеләр турында, ремонтта эшләүче кадрлар турында өзлексез кайгыртучанлык күрсәтергә, аларга уңайлы эш һәм тормыш-көнкүреш шартлары булдыруга аеруча нык әһәмият бирергә тиешләр.

Татарстан АССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда аеруча хезмәт күрсәткән МТС лар һәм МТМ нар өчен премияләр билгеләде. Бу премияләрне алуга ирешү өчен барлык МТС ларда һәм МТМ нарда бөтен мөмкинлекләр бар. Тик бу мөмкинлекләрдән оста файдалануны гына оештырырга кирәк.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

14 нче гыйнварда Мурманск, Ухта һәм Реболы юнәлешләрендә разведчикларның эзләнүләре һәм аерым участкыларда сирәк-сирәк мылтык-пулеметтан атышу булды. Петрозаводск юнәлешендә пехота частьләренең бәрелешләре дәвам итте. Карелия бугазында сирәк-сирәк артиллерия атышуы һәм разведка партияләренең хәрәкәтләре булды.

Безнең авиация берничә тапкыр разведка очышлары үткәрде.

ЧИТ ИЛ ЭШЛӘРЕ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫНДА

1. СОВЕТ—ШВЕЦИЯ ҺӘМ СОВЕТ—НОРВЕГИЯ МӨНАСӘБӘТЛӘРЕНӘ КАРАТА

Соңгы вакытта Совет хөкүмәтенең игтибары Швециядә һәм Норвегиядә урын алган кайбер фактларга юнәлдерелде. Һәр ике илнең хөкүмәтләренә якын торган матбугат органнары һәм кайбер рәсми кешеләр, Швеция һәм Норвегия властьларының юл куюы һәм булышлык күрсәтүе белән, СССР га каршы киң кампания җәелдерергә һәм югарыда күрсәтелгән ике илнең хөкүмәтләре тарафыннан иглан ителгән нейтралитет политикасы белән бергә сыеша алмый торган хәрәкәтләр башларга керештеләр.

Шушы фактлар уңае белән СССР Хөкүмәте, югарыда әйтелгән һәр ике илнең хөкүмәтләренә тиешле белдерүләрне ясауны үзенең Швециядәге һәм Норвегиядәге полпредларына тапшырды.

СССР ның Швециядәге полпреды иптәш Коллонтай 5 нче гыйнварда Швециянең чит ил эшләре министре Гюнтер әфәндегә Совет Хөкүмәте исеменнән белдерү тапшырды. Бу белдерүдә түбәндәгеләр әйтелде:

„Советлар Союзына дошман булган даирәләр һәм матбугат, үзләренең җитәкчелегендә хөкүмәткә якын торган „Социалдемократен“ газетасы белән берлектә, бөтен декабрь ае буена Советлар Союзына каршы һич тәгафу ителмәслек кампания алып бардылар. Бу кампанияне бары тик Швеция СССР белән сугыш хәлендә булган хәлдә генә яки СССР белән сугышка хәзерләнгән хәлдә генә аңлатырга мөмкин булыр иде“.

Аннан соң полпредның белдерүендә, Швеция матбугатында Советлар Союзына каршы сугышка турыдан-туры чакырулар һәм Рюти-Таннер хөкүмәте ягында торган хәлдә СССР га каршы сугышка Швециянең кораллы катнашуын таләп итүләр урын алганлыгы күрсәтелә.

Югарыда күрсәтелгән һәм СССР белән Швеция арасында кискен мөнасәбәтләр китереп чыгаруга исәпләнгән кампаниягә Швеция хөкүмәте тарафыннан каршылык күрсәтелми. Ул гына да түгел, кайбер рәсми кешеләр Рюти-Таннер хөкүмәтенә сугыш ярдәме оештыруда ачыктан-ачык катнашалар. 7 нче декабрьдә, Швеция властьларының ачыктан-ачык яклавы белән, Швециянең күп кенә шәһәрләрендә 47 гә якын вербовка бюролары ачылды. Шушы бюролар тарафыннан тупланган „доброволецларның“ саны меңнәрчә кешеләр белән санала. 28 нче декабрьгә караган кайбер маглүматлар буенча, Швециядән Финляндиягә 10 меңгә якын шундый „доброволец“ килгән. Шуннан соң, көньяк һәм үзәк Швециядән Финляндиягә „доброволецларның“ ике корпусы чыгып киткәнлеге хәбәр ителде. Аларга гомуми командалык итү эшен Швеция генералы Эрнст Линдер кабул иткән.

Швеция матбугатының югарыда әйтелгән кампаниясенә, СССР га каршы сугыш хәрәкәтләренә чакыруларга һәм Швеция властьларының булышлыгы белән ачыктан-ачык „доброволецлар“ отрядлары төзүгә чакыруларга,—Рюти-Таннер хөкүмәтен Швециядән корал белән турыдан-туры тәэмин итүне һәм Финляндиягә Швеция аркылы сугыш тәэминатының барлык төрләрен үткәрергә рөхсәт бирүне өстәргә кирәк.

Чит ил эшләре министренә СССР ныңШвециядәге полпредының белдерүе түбәндәгечә тәмам ителде:

„СССР Хөкүмәте Швеция хөкүмәтенең игтибарын югарыда китерелгән фактларга һәм Швеция властьларының СССР га каршы булган хәрәкәтләренә юнәлдерә. Швеция властьларының бу хәрәкәтләре Швециянең нейтралитет политикасына каршы килеп кенә калмый, бәлки Швеция белән Советлар Союзы арасындагы мөнасәбәтләрдә аның кирәксез кискенлекләргә китерүе мөмкин икәнлекне СССР Хөкүмәте Швеция хөкүмәтенә белдерүне вакытлы дип саный“.

Шул ук 5 нче гыйнварда СССР ның Норвегиядәге илчесе иптәш Плотников Норвегия чит ил эшләре министре Кут әфәндегә СССР Хөкүмәте исеменнән шулай ук белдерү тапшырды. Бу белдерүдә түбәндәгечә әйтелде:

„Норвегиядә хөкүмәткә якын торган кайбер даирәләр һәм Норвегия матбугаты соңгы вакытта Советлар Союзына каршы һичбер нәрсә белән дә туктатылмый торган кампания алып баралар, бу кампаниянең Совет Социалистик Республикалар Союзы белән Норвегия арасындагы мөнасәбәтләрдә зарардан һәм кискенлекләрдән башка бер нәрсәгә дә китерүе мөмкин түгел“.

Аннан соң полпредның белдерүендә, Норвегия матбугатында, СССР га каршы сугышка турыдантуры чакырулар белән бер рәттән, Норвегия хөкүмәтенең Советлар Союзына каршы Рюти-Таннер хөкүмәтенә сугыш ярдәме бирүен таләп итүләр урын алганлыгы күрсәтелде. Стортинг президенты Хамбро әфәнде, капитан—генерал Орфлит һәм башкалар шикелле кайбер рәсми кешеләр бу кампаниягә булышлык күрсәтәләр һәм хәтта анда актив рәвештә катнашалар. Финляндия территориясендә СССР га каршы сугыш уты кабындырып җибәрү өчен Норвегиядә вербовка комитетлары оештырыла. Финляндия өчен Осло группасы илләренең „доброволецларыннан“ аерым дивизия төзелү турында маглүматлар бар. Бер үк вакытта, Норвегия властьларының яклавы белән, Рюти - Таннер хөкүмәтен Норвегиядән тәэмин итү эше алып барыла һәм Финляндиягә Норвегия аркылы сугыш кирәк-яракларының төрле төрләрен үткәрү эше бара. Норвегия чит ил эшләре министренә СССР полпредының белдерүе түбәндәге сүзләр белән тәмам ителде:

„СССР Хөкүмәте югарыда күрсәтелгән фактларга һәм Норвегия властьларының Советлар Союзына каршы булган хәрәкәтләренә Норвегия хөкүмәтенең игтибарын юнәлдерә. Норвегия властьларының күрсәтелгән хәрәкәтләре Норвегия хөкүмәте тарафыннан иглан ителгән нейтралитет политикасына тупас рәвештә каршы килеп кенә калмыйлар, бәлки аларның кирәксез кискенлекләргә китерүләре һәм СССР белән Норвегия арасындагы үзара нормаль мөнасәбәтләрне бозулары мөмкин икәнлекне СССР Хөкүмәте Норвегия хөкүмәтенә белдерүне һич кичектерелмәслек эш дип саный“.

Норвегиянең чит ил эшләре министре Кут әфәнде 6 нчы гыйнварда СССР ның Норвегиядәге полпреды иптәш Плотниковка Норвегия хөкүмәтенең җавабын тапшырды.

Норвегия хөкүмәте үзенең җавабында, нейтралитетны бозуга карата үзенә каршы куелган гаепләрне дөрес булмаган информациягә нигезләнәләр, дип күрсәтә. Норвегия матбугатында Советлар Союзына каршы чыгышлар частный кешеләрдән килеп чыгалар һәм җаваплы даирәләр бу чыгышларны яхшы дип тапмыйлар. Норвегиядә вербовка комитетлары оештырылуга килгәндә исә, Норвегия хөкүмәте аларга бер нинди булышлык та күрсәтми. Норвегиядә чит ил дәүләтендәге хәрби хезмәткә туплау эше закон тарафыннан тыела һәм шуңа күрә рөхсәт ителә алмый. Финляндиягә корал яки сугыш кирәк-яраклары җибәрүгә дә Норвегия властьлары булышлык күрсәтмиләр. Әгәр дә аерым кешеләр үз теләкләре белән сугышта катнашу өчен чит илгә баралар икән, бу, Норвегия хөкүмәтенең фикеренчә, нейтралитетны бозу булып тормый. Норвегия аркылы корал үткәрү дә халыкара хокукка каршы килми. Шуңа да карамастан, Норвегия хөкүмәтенә маглүм булганча, хәзергә кадәр Финляндиягә Норвегия аркылы сугыш материаллары үткәрүнең урын алганы юк, ә Норвегиядән шундый төстәге тәэминатны хосуси рәвештә чыгару бары тик иң аз күләмнәрдә генә бара.

Норвегия хөкүмәтенең җавабы түбәндәгечә ышандыру белән тәмам ителгән: Норвегия „хәзергә кадәр, чит ил дәүләтләрендәге сугышка карата үзе тарафыннан иглан ителгән нейтралитетны саклап килде һәм киләчәктә дә сакларга тели. Норвегия хөкүмәте, СССР белән Норвегия арасында үзара дуслык мөнасәбәтләренең киләчәктә дә яшәячәгенә ышаныч белдерә“.

СССР ның Швециядәге полпредының белдерүенә чит ил эшләре министре Гюнтер әфәнде дә 10 нчы гыйнварда үзенең җавабын бирде.

Швеция хөкүмәте үзенең җавабында, Швеция халкының Финляндиягә кайнар мәхәббәт күрсәтүен, бу мәхәббәтнең матбугатта чагылуын белдерә. Ләкин, Швециянең конституция законнары матбугатка бирелгән ирекне арттырып җибәрүләргә комачаулыйлар,—аерым алганда, чит ил державаларын һәм аларның вәкилләрен мәсхәрәләүгә комачаулыйлар. Швеция хөкүмәтенең фикеренчә, матбугатка карата ул хөкүмәтнең позициясе дә, башка нинди булса да өлкәдә аның хәрәкәтләре дә, Швециягә каршы гаепләүләр өчен Советлар Союзына сылтау бирмиләр. Куелган гаепләүләр нигездә дөрес булмаган информациягә таяныла. Аерым алганда, Швеция доброволецларын туплауга карата булган раслаулар фактларга туры килми. Доброволецлар җыю бары тик частный инициатива белән генә үткәрелә һәм аларның саны Совет Хөкүмәте тарафыннан күрсәтелгән саннарга туры килми. Швециянең власть органнары доброволецлар җыюга булышлык күрсәтмиләр, һәм Швеция службасының офицерлары һәм рядовойлары фин сугышында доброволецлар булып катнашмыйлар.

Финляндиягә Швециядән чыгарыла торган төрле төрдәге әйберләр яки башка илләрдән транзит белән бара торган әйберләр транспортының каршылыклар китереп чыгаруы мөмкин түгел. Швеция башка илләр белән үзенең сәүдә мөнасәбәтләрен сакларга омтыла. Финляндия үзендә сорау булган төрле төрдәге товарларны Швециядән кертә ала һәм Швеция аркылы транзит белән үткәрә ала. Швеция хөкүмәте мондый хәлне үзгәртүне һәм Швеция белән Финляндия арасындагы коммерческий товар оборотын кыенлаштыруны мөмкин дип санамый.

Швеция хөкүмәтенең җавабы түбәндәге ышанычны белдерү белән тәмам ителә: „Швеция белән СССР арасында килеп чыгарга мөмкин булган аңлашылмаучылыкларны югарыда китерелгән фикерләр юкка чыгарырлар һәм СССР хөкүмәтенә Швеция хөкүмәтен гаепләү өчен нигезләр юк икәнлекне исбат итәрләр. Швеция хөкүмәте СССР га каршы агрессив политика алып бармый һәм Советлар Союзы белән Швеция арасындагы үзара мөнасәбәтләрдә нинди дә булса аңлашылмаучылыкларны булдырмаска тели“.

Норвегия һәм бигрәк тә Швеция хөкүмәтләре тарафыннан СССР хөкүмәтенең мөраҗәгатенә бирелгән җавапны тулысынча канәгатьләнерлек дип танып булмый. Норвегия һәм Швеция хөкүмәтләре үзләре тарафыннан нейтралитет политикасының бозылуын күрсәтә торган фактларның барсын да юкка чыгармыйлар. Швеция һәм Норвегия хөкүмәтләренең мондый позициясе үзендә куркыныч саклый. Ул, Швецияне һәм Норвегияне СССР га каршы сугышка кертергә омтылучы державаларның йогынтысына Швеция һәм Норвегия хөкүмәтләренең тиешле каршылык күрсәтмәүләрен күрсәтә.

2. СОВЕТ—ВЕНГРИЯ МӨНАСӘБӘТЛӘРЕНӘ КАРАТА

Венгриянең Москвадагы илчесе Криштоффи әфәнде кичә, 14 нче гыйнварда, Чит Ил Эшләре Халык Комиссары урынбасары иптәш В. П. Потемкинда булды һәм аңарга түбәндәге рәсми белдерүне ясады:

Венециядә Венгрия чит ил эшләре министре Чако белән Италия чит ил эшләре министре Чиано арасында күптән түгел генә булган сөйләшүләргә карата соңгы вакытта тенденциоз хәбәрләр таратыла. Югарыда әйтелгән Италия—Венгрия сөйләшүләре, имештер, Советлар Союзына каршы юнәлдерелгән, дип раслыйлар. Венгрия хөкүмәте бу раслауларны иң кискен формада юкка чыгаруны кирәк дип саный. Венгрия хөкүмәте, Венециядә нинди дә булса дәүләтләр блогын оештыру мәсьәләсе тикшерелмәгәнлекне өстәүне урынлы дип саный.

Криштоффи әфәнде югарыда китерелгән белдерүне Советлар Союзы Хөкүмәтенең игтибарына җиткерүне үтенде.

КҮП СТАНОКЧЫЛАР ЭШЕНЕҢ МАТУР НӘТИҖӘЛӘРЕ

Күп станокчылар Казан киез итек-фетр фабрикасында торган саен күбрәк урын ала баралар. Хәзерләү цехы стахановчылары күп станокта эшләүгә фабрикада беренче булып керештеләр. „Американка“ машинасында эшләүче Шәйхетдинова һәм Ахунова иптәшләр бу хәрәкәт башлану белән берьюлы ике машинада эшләүгә күчтеләр һәм бик яхшы эш үрнәкләре күрсәттеләр. Хәзер „Американка“, тарау һәм тетү машиналарында эшләүчеләрнең барсы да икешәр машинада эшлиләр. Алар ике машинада эшли башлауның беренче көннәрендә үк хезмәт җитештерүчәнлегенең югары күрсәткечләрен бирә башладылар.

„Американка“ машиналарында эшләүче Шәйхетдинова һәм Ахунова иптәшләр хәзер көнлек норманы 200—250 процент итеп үтиләр. Тарау машиналарында эшләүче Бариева, Галиуллина, Петрова, Попова, Владимирова, Суханкулова һәм Позднерова иптәшләр ике машинага билгеләнгән норманы 150—180 процент итеп үти башладылар.

Әгәр дә моңа кадәр катлаулы тарау машиналарының һәр берсендә бер ярдәмче эшче булса, хәзер бер ярдәмче эшче берьюлы 4 машинага хезмәт күрсәтә.

Механика цехы стахановчылары да бу гүзәл хәрәкәткә кушылдылар. Элек һәр цехта бер дежур электромонтер эшләсә, хәзер, эш сәгатьләреннән тулысынча файдалану нәтиҗәсендә, бер дежур электромонтер берничә цехка хезмәт күрсәтә башлады.

Фабрикада берничә төрле профессияне үзләштерүчеләр хәрәкәте дә киңәя. Мәсәлән, фетр производствосында эшләнеп чыккан продукцияне сортларга аеручылар бер үк вакытта ул продукцияне тапшыру эшен дә башкаралар.

Алдынгы стахановчыларның күп станокларда эшләүгә күчүләре һәм берьюлы берничә төрле профессияне үзләштерүләре аз сандагы эшчеләр белән күп продукция җитештерү мөмкинлеген бирде. Мәсәлән, хәзерләү цехындагы тарау машиналарында элек 24 кеше эшли иде, хәзер 12 кеше эшли. Фетр производствосындагы тарау машиналарында элек 12 кеше башкара торган эшне хәзер 6 кеше башкара.

Вахитов жиркомбинатының механика цехында күп станокларда эшләүче стахановчы А. Н. Ткачев иптәш планын системалы рәвештә 200 процент үти. Б. Мясников фотосы. (ТатТАСС фотохроникасы).

Шулай итеп, тарау машиналарында эшләүчеләрнең 50 проценты хәзер башка эшләргә күчерелделәр. Фабрикада элек 21 электромонтер эшләсә, хәзер шул ук эшне 14 кеше башкара. Фрезировщиклар һәм токарьлар саны 50 процентка кыскартылды.

Фабрикада күп станокларда эшләүчеләр саны көннән-көн арта бара. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә гаять зур әһәмияте булган күп станокчылар хәрәкәтен тагын да киңрәк җәелдерү өчен фабрикада зур мөмкинлекләр бар. Ләкин партия, профсоюз һәм комсомол оешмаларының шулай ук инженер-техник работникларының күп станокларда эшләүчеләргә җитәкчелек итүләре канәгатьләнерлек түгел әле. Күп станокларда эшләүчеләрнең уңышлы эш тәҗрибәләре башкалар арасында уртаклашылмый. Тәҗрибә уртаклашу киңәшмәләре үткәрелми. Цехларда күп станокчыларга тиешле шартлар тудырылмаган. Машиналарны кечкенә генә сәбәпләр аркасында еш кына эшсез тоту фактлары бар.

Ф. Сагдеева.

ВКП(б) ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮЧЕЛӘРГӘ ЯРДӘМГӘ

ЛЕНИНЧЕЛ-СТАЛИНЧЫЛ КООПЕРАТИВ ПЛАН

Партиянең Сталинчы Үзәк Комитетының май Пленумы карарлары колхоз төзелешенең төп мәсьәләләренә кагылдылар. Пленум билгеләгән чаралар авыл хуҗалыгы артелен тагын да ныгытуга юнәлдерелгәннәр, колхозчының шәхси хуҗалыгын күпертүгә каршы көрәшкә юнәлдерелгәннәр. Бу чаралар бөтенләе белән партиянең XVIII нче съезды карарларыннан килеп чыгалар, һәм алар партиянең илебездә сыйныфларны һәм сыйнфи аермаларны тулысынча бетерүгә юнәлдерелгән политикасында иң әһәмиятле буын булып торалар. Үзәк Комитет Пленумының тарихи карарларының магнәсен дөрес аңлау өчен крестьяннәрне социалистик яңадан тәрбияләү турында Ленин—Сталин таглиматын үзләштерергә, Ленинчел-Сталинчыл кооператив планны өйрәнергә кирәк.

* * *

Ленинчел-Сталинчыл кооператив планның әһәмияте нәрсәдә, аның төп магнәсе нәрсәдә һәм ул ничек үткәрелде? Күпләр алдына табигый рәвештә килеп баса торган сораулар әнә шулар.

Буржуазия тарафыннан һәм хосуси милекчелеккә нигезләнгән бөтен җәмгыят системасы тарафыннан „авыл тормышының идиотизмы"на китереп кертелгән вак крестьяннәрне тартып алу өчен, берләшүнең кооператив формасыннан җиңеп чыккан пролетариатның файдаланачагын заманында Маркс һәм Энгельс алдан ук әйткәннәр иде.

Энгельс болай дип язды:

„Коммунистик хуҗалыкка күчкәндә безгә кооператив производстводан кин күләмдә файдаланырга кирәк булачакка Маркс та, мин дә бер вакытта да шик тотмадык" (Ф. Энгельс „Политик Васыят", 1922 нче ел басмасы, бит 21).

Капиталистик җәмгыяттә крестьяннәрнең эксплуатацияләнүенә Маркс һәм Энгельс тирән һәм ачык характеристика бирделәр. Игенчелектә вак производство өстен торганда кешеләрнең гаять күп көчләре әрәм була. Производство средстволары бүлгәләнгән була. Крестьян авыр хезмәттә җәфа чигә. Җитештерүчеләр берберләреннән аерылган булалар. Җир власты крестьянне кечкенә җир кисәгенә бәйләп тота, крестьян шушы милекчелек күләгәсенә ябышып ята, котылу юлын шуннан эзли. Ләкин ул үзенең хәле буенча капитал колы. Бик күп вак крестьяннәр үзләренең хәлләре буенча пролетариатка керәләр, ләкин алар үзләре моны төшенмиләр. Крестьяннең вак хосуси милекчелеге аның үзенең авыр хәлен аңлавына комачаулый.

Вак игенчелек крестьянне хәерчелектән һәм ачлыктан коткара алмый. Моңа бары тик вак крестьяннәрне берләштергәндә генә, аларны кооперативлаштырганда гына ирешергә мөмкин.

Ләкин капитал хөкем сөргәндә кооперация дә крестьяннәрне хәерчелектән чыгара алмый: капитализм дөньясында кооперация крестьяннәрне капиталистик эксплуатацияләү формаларының берсе булды һәм булып тора. Буржуа илләрдә кооператив предприятиеләре частьный капитал белән бергә кушылалар һәм аларның эксплуататорлык политикасын үткәрүче булып торалар. Шунлыктан, Ленин күрсәткәнчә, иске кооператорларның (Роберт Оуенның һәм башкаларның) фантазияләре тормышка ашмаслык хиял. Бу кооператорлар кооперация ярдәме белән капитализмны тыныч рәвештә үзгәртү турында хиялландылар. Алар сыйнфи көрәштән читләштеләр. Алар, эшчеләр сыйнфы тарафыннан власть яулап алынганнан соң гына кооперациянең нәтиҗәле социалистик көч алачагын аңламадылар.

Эшчеләр сыйнфы диктатурасы булганда, җирләргә, банкларга, эре индустриягә, транспортка национализация ясалган булганда, команда югарылыклары эшчеләр сыйнфы кулында тупланган шартларда кооперация шундый канал булып әверелә ки, аның аркылы эшчеләр сыйнфы үзенең союзнигы булган крестьяннәр белән экономик хезмәттәшлек итә һәм сыйныфларны бетерү юлыннан, муллык, материаль яктан тулы тәэмин ителү, культураның чәчәк атуы юлыннан крестьяннәрне алып бара.

Эшчеләр сыйнфы диктатурасы булганда, эшчеләр сыйнфы белән крестьяннәр арасындагы экономик хезмәттәшлекнең характеры конкрет тарихи шартларга, экономик обстановкага, сыйнфи көчләрнең мөнасәбәтләренә бәйле була. Крестьян хуҗалыкларын кооперативлаштыруның характеры, аның роле Совет дәүләтенең үсүе белән бик нык үзгәрде.

Ленинчел-Сталинчыл кооператив планның үзенчәлеге шуннан гыйбарәт ки, социализмның көчләре үсә барган саен, дәүләтнең экономик команда югарылыклары ныгый барган саен, эшчеләр сыйнфы крестьяннәрне кооперациянең түбән формаларыннан югары формаларына алып барды.

Иптәш Сталин болай диде:

„...колхозлар кооперациянең бер төре, производство кооперациясенең иң ачык төре ул. Товар үткәрү кооперациясе бар, тәэминат кооперациясе бар, производство кооперациясе дә бар. Колхозлар гомумән кооперация хәрәкәтенең, аерым алганда Ленин кооперация планының аерып алынмаслык кушма өлешен тәшкил итәләр. Ленинең кооперация планын тормышка үткәрү, бу—крестьяннәрне тәэминат кооперациясеннән, аларның продуктларын сату кооперациясеннән производство кооперациясенә, колхоз кооперациясенә дип әйтик, күтәрү дигән сүз ул..." („Ленинизм мәсьәләләре", бит 246).

Хәзерге этапта артель—производство кооперациясенең, колхоз кооперациясенең төп формасы.

Артельдә производствоның хәл иткеч төп средстволары җәмагатьләштерелгән. Артель—хуҗалыкның социалистик формасы.

Марксизм-ленинизм болай дип өйрәтә: эшчеләр сыйнфы крестьяннәр белән союзда булганда гына җиңә ала, бу союзда җитәкчелек роле эшчеләр сыйнфы кулында. Крестьяннәр дә үз чиратларында **бары тик эшчеләр сыйнфы белән союзда булганда гына, бары тик эшчеләр сыйнфы җитәкчелегендә генә** тулы экономик азатлыкка, культура һәм материаль яктан рәхәт тормышка ирешә алалар. Димәк, эшче һәм крестьяннәрнең төп интереслары тулысынча бер-берсенә туры килә. Күп миллионлы вак крестьяннәр сыйныфларны бетерү белән, һәр төрле эксплуатацияне юк итү белән кызыксыналар. Ләкин сыйныфларны тудыра торган нәрсәне, ягни производство средстволарына хосуси милекчелекне бетерми торып, сыйныфларны бетерү мөмкин түгел. Ленин һәм Сталин, крестьяннәрне бары тик гомуми хезмәттә генә, эре машина техникасы нигезендә генә социалистик рухта яңадан тәрбияләргә мөмкин дип өйрәтәләр.

Партиянең X нчы съездында Ленин болай диде:

„Вак игенчене яңадан тәрбияләү, аның бөтен психологиясен һәм гадәтләрен яңадан тәрбияләү эше буыннарга сузыла торган эш ул. Вак игенчегә карата бу мәсьәләне хәл кылуны, әйтик, аның бөтен психологиясен сәламәтләндерүне материаль база гына, техника гына, игенчелек эшендә масса-күләмдә, тракторлар һәм машиналар куллану гына, масса-күләмдәге электрификация генә булдыра ала". (Том XXVI, бит 239).

Димәк, вак крестьян хуҗалыкларының алдынгы эре машина техникасын кин күләмдә куллануга нигезләнгән эре җәмагать хуҗалыгына күчүләре сыйныфсыз социалистик җәмгыятькә күчү өчен котылгысыз кирәкле, мәҗбүри шарт.

Ленин „Вак хуҗалык белән мохтаҗлыктан чыгып булмый" дип өйрәтә. (Том—XXIV бит 540).

Вак крестьян үзенең аз гына җир кисәген казынып ятканда аның алдында һәр вакыт хәерчелек торачак. Крестьян материаль яктан тулы тәэмин ителүгә бары тик югары җитештерүчәнлекле, эре хуҗалык нигезендә генә, ягни колхозлар нигезендә генә ирешә алачак.

Большевиклар партиясе безнең совет крестьяннәренә бу юлны ачты һәм алар большевиклар артыннан киттеләр.

Бөек Октябрь революциясеннән соң крестьяннәр өчен яңа юл, колхозлар юлы башланды.

Кай вакыт шундый сорау бирәләр: ни өчен массовый коллективлаштыру социалистик Октябрь революциясеннән соң ук җәелеп китмәде? Ни өчен 1929 нчы елны гына—бөек борылыш елында гына—крестьяннәр күпләп колхозларга керә башладылар.

Колхозларның җиңүе өчен зур хәзерлек кирәк иде. Коллективлаштыру өчен материаль база төзергә, крестьяннәрне үзләренең эшләрен бергәләп алып баруга хәзерләргә кирәк иде. Ленин болай диде:

„Коммунистик җәмгыяттә урта хәлле крестьяннәр бары тик без аларның экономик тормыш шартларын җиңеләйткән һәм яхшырткан чакта гына безнең якта булырлар. Әгәр дә без иртәгә беренче дәрәҗәдәге 100 мең трактор бирә алсак иде һәм аларны бензин белән тәэмин итә алсак, аларны машинистлар белән тәэмин итә алсак иде (сез бик яхшы беләсез, хәзергә бу әле фантазия), ул чакта урта хәлле крестьян: „мин коммуна яклы" (ягни коммунизм яклы) дияр иде. Ләкин моны эшләү өчен башта халыкара буржуазияне җиңәргә кирәк, аны безгә шул тракторларны бирергә мәҗбүр итәргә кирәк, яки, ул тракторларны без үзебез бирә алырлык дәрәҗәдә җитештерүчәнлегебезне күтәрергә кирәк. Бары тик шулай булганда гына бу мәсьәлә дөрес куелачак" (XXIV том, 170 бит).

1925 нче ел азагында партиянең XIV нче съездында игълан ителгән Сталинчыл индустрияләштерү планының җиңүе коллективлаштыру өчен материаль база тудырды.

Ләкин колхозларның җиңүе өчен материаль база гына җитми иде әле. Берләшүнең иң гади формаларының тирән катлауларында крестьяннәрне үз эшләрен бергәләп алып баруга өйрәтергә кирәк иде. Крестьяннәрне кинәт кенә, хәзерлексез генә колхозларга тартырга ярамый иде. Вак крестьяннең ике төрле табигатен партия һәр вакыт нык искә алды, крестьяннең бер яктан—милекче, икенче яктан—хезмәт иясе булуын һәр вакыт искә алды.

„Кооперация турында" дигән мәкаләсендә Ленин аерым җитештерүчеләрнең шәхси интересларын дәүләт интереслары белән оста рәвештә бергә кушарга, шәхси интересларны җәмагать интересларына буйсындырырга партияне өйрәтте.

Кооперациянең түбән формалары (потребитель, товар үткәрү, тәэминат кооперациясе һ. б.) кооперация хәрәкәтенең башлангыч формалары, аның башлангыч этапы булдылар.

Кооперациянең бу түбән формалары вак крестьян хуҗалыгының нигезләренә кагылмадылар. Шулай да маглүм бер этапта аларның әһәмияте зур булды. Чөнки алар крестьяннәрне кооператив җәмагатчелеккә күнектерделәр, күп миллионлы вак крестьяннәргә дәүләтнең җитәкчелеген җиңеләйттеләр, дәүләтнең социалистик промышленностьы белән вак крестьян хуҗалыгы арасындагы элемтәгә ярдәм иттеләр.

Коллективлаштыру өчен материаль база тудырылганга кадәр, крестьяннәрне коллективлашуга хәзерләгәнгә кадәр һәм аның файдалы булуына алар үз тәҗрибәләрендә ышанганга кадәр, партия социалистик төзелешне урта хәлле крестьян экономикасына карата тып алып барды һәм игенчелекнең җитештерүче көчләрен кооперациянең түбән формалары нигезендә күтәрде.

Массовый коллективлаштыру өчен материаль база хәзерләнгәнгә кадәр, партия, капиталистик элементларны чикләү политикасын үткәрде. Вак крестьян хуҗалыгыннан кулаклар үсеп чыкты. Алар урта хәлле крестьянне үз якларына тартырга омтылдылар. Крестьян өчен көрәш барды—„кем кемне?". Крестьяннәрне партия җитәкчелегендә эшчеләр сыйнфы үз артыннан ияртеп алып барырмы, әллә хезмәт ияләренең явыз дошманнары булган кулаклар крестьяннәрне үз артларыннан ияртеп барырлармы?

Эшчеләрнең крестьяннәр белән союзын троцкичы-бухаринчы кабахәтләр корткычларча өзәргә омтылдылар һәм урта хәлле крестьянне кулак кочагына этәрделәр. Ләкин троцкичы-бухаринчы кабахәтләр каты отпор алдылар. Кулаклар һәм аларның троцкичы-бухаринчы һәм буржуаз милләтче агентлары тар-мар ителде.

Тоташтан коллективлашуга кадәр безнең халык хуҗалыгы ике төрле нигездә үсте: бер яктан, дәүләтнең социалистик эре промышленность нигезендә һәм, икенче яктан, аз җитештерүчән вак крестьян хуҗалыгы нигезендә. Бу хәл озак дәвам итә алмый иде.

Иптәш Сталин болай диде:

„Бер туктаусыз, ягни артык озак вакыт буена, Совет властын һәм социалистик төзелешне ИКЕ ТӨРЛЕ базага, иң эре һәм берләштерелгән социалистик промышленность базасына һәм вак товарлыклы иң таркау һәм артта калган крестьян хуҗалыгы базасына нигезләргә ярамый. Авыл хуҗалыгын акрынлап, ләкин системалы һәм ныклы рәвештә яңа техник базага, эре производство базасына күчерергә, аны социалистик промышленность дәрәҗәсенә кадәр күтәрергә кирәк. Я без бу бурычны хәл итәрбез,—һәм ул вакытта тәмам җиңү хәл ителгән булыр, яисә без аннан читкә китәрбез, бу бурычны хәл итмәбез,—һәм ул вакытта капитализмга кире кайтуның котылгысыз хәл булып әверелүе мөмкин" („Ленинизм мәсьәләләре". 9 нчы басма, бит 362).

Вак индивидуаль крестьян хуҗалыгы аз җитештерүчән. Ул эре машина техникасын куллана алмый. Андый хуҗалыкның товарлыклыгы бик түбән. Ә безнең шәһәрләребез үстеләр; күп сандагы яңа заводлар һәм фабрикалар авыл хуҗалыгы чималына да, азыкка да сорауны арттырдылар. Игенчелектә вак крестьян хуҗалыгының түбән товарлыклы булуы бездә икмәк мәсьәләсендә 1926—1928 нче елларда булган кыенлыкларның төп сәбәбе иде.

Җәмагатьләштерелгән эре социалистик производствога күчәргә кирәк иде. Иптәш Сталин безне шушы юл белән алып барды. Эре кулак хуҗалыгын торгызырга, СССР да капитализмны яңадан урнаштырырга омтылган троцкичы-бухаринчы кабахәтләрнең җинаятьле уйларын ул фаш итте.

Иптәш Сталин авыл хуҗалыгын социалистик үзгәртеп кору программасын даһиларча эшләп, ленинчел кооператив планны төзеп һәм баетып бу программаны үткәрүгә нык җитәкчелек итеп, илебездә колхоз төзелешенең тулы җиңүен тәэмин итеп, һәм шуның белән революцион марксизмның бөтен даһилыгын гәүдәләндерде.

1927 нче елның азагында партиянең тарихка коллективлаштыру съезды булып кергән XV нче съездында иптәш Сталин партия алдына түбәндәге бурычны куйды:

„... халык хуҗалыгында капиталистик элементларны бетерүгә таба юл алып, шәһәрдә дә, шулай ук авылда да халык хуҗалыгының барлык тармакларында социалистик команда югарылыкларын киңәйтергә һәм ныгытырга" (И. Сталин. ВКП(б) ның XV нче съездында Үзәк Комитетның политик отчоты, бит 25).

Аннары, вак крестьян хуҗалыгының артта калганлыгын һәм аз җитештерүчәнлеген әйтеп, иптәш Сталин бу хәлдән котылу юлы кайда икәнлекне күрсәтте.

Иптәш Сталин болай диде:

„Котылу юлы, вак һәм таркау крестьян хуҗалыкларының җирне җәмагать белән эшләү нигезендә эре һәм берләштерелгән хуҗалыкларга күчүендә, яңа, югары техника базасында җирне коллектив булып эшләүгә күчүдә. Котылу юлы, акрынлап, ләкин бер туктаусыз, кысу тәртибендә түгел, бәлки күрсәтү һәм ышандыру тәртибендә, авыл хуҗалыгы машиналары һәм тракторлар куллану белән, игенчелекне интенсификацияләүнең фәнни алымнарын куллану белән, вак һәм иң вак крестьян хуҗалыкларын җирне җәмагать булып, иптәшләрчә, коллектив эшләү нигезендә эре хуҗалыкларга берләштерүдә. Башка төрле котылу юллары юк" (шунда ук, бит 31).

Партиянең XV нче съезды коллективлашуны бөтен юллар белән җәелдерү турында карар чыгарды.

Шуның белән бергә съезд түбәндәге директиваны бирде:

„..кулакларга каршы һөҗүмне тагын да җәелдерергә һәм авылда капитализмның үсүен чикләүче һәм крестьян хуҗалыгын социализмга таба алып баручы күп кенә чаралар күрергә" („ВКП(б) резолюцияләрдә", кисәк II, бит 260).

XV нче съезд карары практикада да тиз тормышка ашырыла башлады. Партия, кулакларга каршы кискен һөҗүмгә күчеп, аларның саботажын рәхимсез рәвештә җиңде. Колхоз хәрәкәте тиз киңәйде.

Бөек борылыш елы массовый колхоз хәрәкәте елы булды.

Совет крестьяннәре, макталган хосуси милекчелек байрагын кискен рәвештә ерттылар һәм коллективизм юлына, социализм юлына күчтеләр.

Иптәш Сталин партиянең политикасында тамырдан борылышны, кулакларның эксплуататорлык тенденцияләрен чикләү политикасыннан яңа политикага—тоташтан коллективлашу базасында кулакларны сыйныф булу ягыннан бетерү политикасына борылуны билгеләгән тарихи лозунгны игълан итте.

„Бу—гаять тирән революцион борылыш, җәмгыятнең иске сыйфат хәленнән яңа сыйфат хәленә сикереш иде, үзенең нәтиҗәләре буенча 1917 нче елның октябрендәге революцион переворотка тиңләшә торган сикереш иде.

Бу революциянең үзенчәлеге шуннан гыйбарәт булды ки, ул, дәүләт власты инициативасы буенча ЮГАРЫДАН эшләнде, бу эшкә ирекле колхоз тормышы өчен кулак кабаласына каршы көрәшкән крестьяннәренең миллионлаган массалары тарафыннан ТҮБӘННӘН турыдан-туры булышлык күрсәтелде". („ВКП(б) тарихының кыскача курсы", бит 344—345).

Тоташтан коллективлаштыру һәм шуның нигезендә кулакларны сыйныф булу ягыннан бетерү турындагы таглиматны тудырып, заманыбызның иң бөек теоретигы иптәш Сталин марксизмны яңа баскычка күтәрде, марксизм-ленинизмның бөек идеяләренә миллионнарча кешеләрне СССР да капитализмны тамырлары белән йолкып ташлау юлы буенча алып барырга сәләтле булган яңа көчне бирде.

Хәзерге этапта колхоз хәрәкәтенең төп һәм иң әһәмиятле формасы булган **авыл хуҗалыгы артеле** турындагы таглиматы белән, колхоз, җәмагать производствосын техник коралландыруның төп этәргече булып **машина-трактор станцияләре** турындагы таглиматы белән иптәш Сталин колхоз хәрәкәтен бердән-бер дөрес юлга юнәлдерде һәм шушы юл гына СССР да социализмның җиңүен тәэмин итә алды.

„Кооперация турында" дигән мәкаләсендә Ленин, крестьяннәрне яңа тәртипләргә мөмкин кадәр **гадиерәк, җиңелрәк һәм ансатрак юл белән** алып барырга кирәк, **һәрбер вак крестьян социализм төзүдә катнаша алырлык** булсын, диде.

Коллективлашу **масса** хәрәкәте булды, ул **ирекле**лек принципларында үткәрелде. Ләкин крестьяннәрне колхозларга тартуда Ленинга каршы булган методларны кулланып, коры сан артыннан куып, коллективлашуны тизләтүче кешеләр килеп чыккач, иптәш Сталин „Уңышлардан баш әйләнү" дигән мәкаләсе белән чыкты. Бу мәкалә башларын югалткан кешеләрнең ашыгып чабуларын туктатты. Иптәш Сталинның бу чыгышы коллективлашу эшендәге бозуларны бетерүгә ярдәм итте һәм колхоз хәрәкәте, крестьяннәрне торган саен күбрәк санда берләштереп, тиз алга китте, ныгыды, үсте.

Колхозчыларның шәхси хуҗалыкларына юл кую кирәклеген игътибарга алмыйча, колхозчыларның бөтен нәрсәләрен күз ачып йомганча җәмагатьләштерергә теләгән кешеләрнең ялгышларын партия төзәтте. Үзләренең шәхси кирәкләре өчен терлекләр булдыруда партия колхозчыларга ярдәм итте, сыерсызлыкны бетерде.

Колхоз төзелеше зур җиңүгә ирешә. Хезмәтчел крестьяннәр үзләренең тормышларын социалистик производство белән нык бәйләделәр.

Крестьяннәрне изеп килгән үткән заман бөтенләйгә һәм мәңгегә югалды. Революциягә кадәр крестьяннәр арасында ярлылар 65 процент, урта хәлләләр 20 процент, кулаклар 15 процент иде. Крестьян йортларының барсының санына карата атсыз йортлар 30 процент, иген кораллары булмаганнары 34 процент, чәчү җирләре булмаган йортлар 15 процент иде. Элекке авылның коточкыч ярлылыгын һәм хәерчелеген күрсәтә торган картина әнә шул!

Бөек Социалистик Октябрь Революциясеннән соң кулакның юлы киселде, ярлылар шактый кимеде, авыл урта хәллегә әверелде. 1928—1929 нчы елларда ярлылар 35 процент, урта хәлле крестьяннәр 60 процент, кулаклар 4—5 процент булды.

Колхоз төзелеше җиңгәннән соң хәл тамырыннан үзгәрде. Тоташтан коллективлашу нигезендә кулаклар бөтенләйгә бетерелделәр. „Кем кемне?" мәсьәләсе ил эчендә тулысынча социализм файдасына хәл ителде. Колхозлар нәтиҗәсендә авылда ярлылык бетерелде. Колхоз төзелеше җиңми торып шәһәрдә һәм авылда эшсезлекне бетерү мөмкин түгел иде. Коллективлашу җәелдергәнгә кадәр шәһәрләрдәге эшсезләр массасының шактый өлеше авыл ярлылары хисабына арта иде.

Хәзер авылда 20—30 миллионлы ач ярлылар юк инде, чөнки алар колхозларга күчтеләр, тәэмин ителгән кешеләр булып әверелделәр һәм уңышлы рәвештә таза тормыш төзиләр.

Капитализм вактында шәһәр авылның актык җилеген суыра, аны эксплуатацияли. Эшчеләр сыйнфы диктатурасы вактында шәһәр авылны бәхетле тормыш юлы белән алып бара. Эшчеләр сыйнфы крестьяннәрнең юлбашчысы, җитәкчесе. Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә, эшчеләр сыйнфы, крестьяннәр белән союзда булып, социализмның барлык дошманнарын тар-мар итте, крестьяннәргә колхоз кырларында шатлыклы, бәхетле хезмәтне тәэмин итте.

Безнең илебез дөньяда игенчелеге иң эре, алдынгы булган ил булып әверелде.

Совет власты колхозларны эре машина техникасы белән коралландырды һәм крестьяннәрне авыр хезмәттән азат итте. **Авыл хуҗалыгы хезмәте инде нигездә индустриаль хезмәтнең бер төре булып әверелде.** Хәзер безнең колхоз кырларында йөз меңнәрчә тракторлар, комбайннар, автомобильләр эшли.

Капитализм илләрендә машина вак крестьяннәргә бөлгенлек, хәерчелек, һәлакәт китерә. Бездә алай түгел. СССР да машина крестьяннәрне материаль һәм рухани культураның иң югары дәрәҗәсенә кадәр күтәрү коралы булып әверелде.

Совет крестьяннәре культуралы таза тормыш юлы белән туктаусыз алга баралар. Күп санда мәктәпләр, балалар ясляләре, уку өйләре, клублар төзелә. Авыл төзекләнә. Электр үткәрелә. Колхоз көнкүрешендә радио көндәлек әйбер булып әверелде.

Шәһәр белән авыл арасындагы каршылык уңышлы рәвештә бетерелә. Колхозчы крестьяннәр арасында интеллигенция тизлек белән үсә. Күп колхозчылар югары белем алалар. Колхозларда индустриаль хезмәт работниклары хәзер инде ун һәм йөз меңнәрчә санала.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе — Ленинчел-Сталинчыл кооператив планның җиңүләрен аеруча ачык күрсәтә. Күргәзмәне ачканда, иптәш Молотов болай диде: „...крестьяннәрне таркау һәм вак хуҗалыклардан җәмагатьләштерелгән социалистик хуҗалык төзүчеләр итеп әверелдергән колхозлар колхозчы совет крестьяннәрен бүген үзләренең хуҗалык ягыннан оешканлыкларындагы, культура үсешләрендәге һәм социалистик аңлылыкларындагы гаять зур уңышларын күрсәтә торган бөек көч итеп әверелдерделәр".

Капитализм вактында берәүләрнең баюы икенчеләрнең бөлүләре, хәерчеләнүләре һәм ачыгулары хисабына бара.

Колхоз төзелеше барлык колхозчыларга колхозда намуслы хезмәт белән үзләренең бәхетле тормышларын һәм культура дәрәҗәләрен өзлексез күтәрергә мөмкинлек бирә. Бездә кешенең кешене эксплуатацияләве мәңгегә бетерелде. Социалистик хезмәт колхозчыга почет та, дан да, материаль байлык та бирә.

Һәрбер колхозчы колхозда башка кеше өчен түгел, бәлки үзе өчен эшләвен, шуның өчен дә колхозның байлыкларын һәр төрле юллар белән арттырырга тиешлеген белергә тиеш.

Ләкин кайбер колхозчылар моны аңлап җиткермиләр әле. Колхозчыларның күпчелек өлеше намус белән эшләгән һәм намуслы хезмәтенең җимешләрен алган вакытта, колхозчыларның бер өлеше җәмагать хуҗалыгына кул селтәп карый, үзенең шәхси хуҗалыгын киңәйтү турында гына кайгырта. Шуның белән авыл хуҗалыгы артеле уставының төп нигезе бозыла.

„Колхозларның җәмагать җирләрен әрәм-шәрәм итүдән саклау чаралары турында" ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карары колхозлардагы буржуаз тенденцияләрне, авыл хуҗалыгы артеле уставын бозуларны бөтен кискенлеге белән ачты.

Бу тенденцияләр колхозларның җәмагать җирләрен әрәм-шәрәм итүдә һәм урлауда, колхоз җирләрен сатып алу—сату фактларында, колхозчыларның шәхси хуҗалыкларын законсыз рәвештә киңәйтүләрендә чагылалар. ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарында күрсәтелгәнчә, бу шуңа алып бара ки, „каралты тирәсе хуҗалык үзенең ярдәмче хуҗалык булу характерын югалта һәм кай вакыт колхозчы доходының төп чыганагына әверелә".

Авыл хуҗалыгы артеленең уставы — авылда яңа җәмгыять төзүнең төп законы.

„Авыл хуҗалыгы артеленең көче һәм өстенлекләре нәрсәдә?
Шунда ки, „а) артель колхозчыларның шәхси, көнкүреш интересларын аларның җәмагать интереслары белән бергә дөрес итеп бәйли, б) артель шәхси интересларны һәм көнкүреш интересларын җәмагать интересларына уңышлы итеп яраштыра, шуның белән кичәге ялгыз хуҗалыкчыларны коллективизм рухында тәрбияләүне җиңеләйтә". (Сталин, „Ленинизм мәсьәләләре", бит 655).

Иптәш Сталинның бу күрсәтмәсе бөтен колхоз төзелеше өчен хәл иткеч әһәмиятле урын тота. Бу аңлаешлы, даһиларча формулада колхозларда шәхси интерес белән җәмагать интересының бергә кушылуы нәрсәдән торганлыгы күрсәтелгән. Ул колхозчыларның **шәхси интересларын җәмагать интересларына яраштыруда** чагыла.

Бу бик аңлаешлы, чөнки җәмагать милке — безнең стройның экономик нигезе. Илебездәге хезмәт ияләренең тормышлары яхшыруның тагын да үсүе тулысынча җәмагать милкенең үсүенә һәм артуына бәйләнгән.

Иптәш Сталин **колхозларга җитәкчелек проблемасын** бөтен яктан эшләде һәм бу эштә үз агымына куюның бөтен зарарын, бөтен һәлакәтен күрсәтте.

Иптәш Сталинның күрсәтмәләрен кулланганда гына, колхозларны дөрес юл белән, социализмның тагын да чәчәк атуы юлы белән, кешенең тормышы өчен кирәк булган бөтен нәрсәнең тулы муллыгы юлы белән алып барырга мөмкин.

Колхозларны ныгыту турында көндәлек кайгыртучанлык, колхоз кырларында намуслы хезмәт — колхозчылар массасының бәхетле тормышының төп чыганагы менә шул, колхозчы крестьяннәрнең рәхәт тормышларының нигезе менә шул.

А. Азизян.

СССР ГОСПЛАНЫ БЕЛДЕРҮЕ

СССР Госпланының Халык Хуҗалыгы Учеты Үзәк Идарәсенең мәглүматлары буенча СССР промышленностының валовой продукциясе, тимер юлларда йөк төяү һәм ваклап сату товар әйләнеше 1938 нче елга чагыштырганда 1939 нчы елны түбәндәге күләмнәрдә үсте:

	1938 ел	1939 ел	1939 нчы ел, 1938 нче елга карата процентларда
I			
Түбәндә саналган гомуми союзный һәм союз-республика наркоматларының дәүләт промышленносты продукциясе (1926/27 нче елгы бәяләрдә, миллион сум белән)	84.103,7	96.462,0	114,7
ГОМУМИ СОЮЗНЫЙ һӘМ СОЮЗ-РЕСПУБЛИКА ПРОМЫШЛЕННОСТЬ НАРКОМАТЛАРЫ:			
Авыр машина төзелеше халык комиссариаты	2.393,4	2.720,4	113,7
Уртача машина төзелеше халык комиссариаты	6.077,9	6.997,8	115,1
Гомуми машина төзелеше халык комиссариаты	2.101,6	2.257,0	107,4
Оборона промышленносты халык комиссариатлары (авиация промышленносты наркоматы, сугыш кирәк-яраклары наркоматы, кораллар наркоматы, судно төзелеше промышленносты наркоматы)	11.556,2	16.935,0	146,5
Күмер промышленносты халык комиссариаты	1.888,0	2.062,5	109,2
Нефт промышленносты халык комиссариаты	2.836,1	2.973,6	104,8
Электростанцияләре һәм электр промышленносты халык комиссариаты	3.837,6	4.117,3	107,3
Кара металлургия халык комиссариаты	5.278,9	5.524,6	104,7
Төсле металлургия халык комиссариаты	1.419,4	1.618,9	114,1
Химия промышленносты халык комиссариаты	3.860,4	4.346,5	112,6
Төзү материаллары халык комиссариаты	1.549,8	1.632,6	105,3
Урман промышленносты халык комиссариаты	2.848,1	2.999,3	105,3
Текстиль промышленносты халык комиссариаты	9.054,5	9.850,8	108,8
Җиңел промышленность халык комиссариаты	7.091,7	7.668,0	108,1
Азык промышленносты халык комиссариаты	10.349,9	11.263,9	108,8
Ит һәм сөт промышленносты халык комиссариаты	3.790,8	4.329,5	114,2
Балык промышленносты халык комиссариаты	846,5	942,6	111,4
Хәзерләүләр халык комиссариаты	2.072,8	2.445,8	118,0
ПРОМЫШЛЕННОСТЬ НАРКОМАТЛАРЫ БУЛМАГАН ГОМУМИ СОЮЗНЫЙ һӘМ СОЮЗ-РЕСПУБЛИКА НАРКОМАТЛАРЫ:			
Юл эшләре халык комиссариаты	1.264,6	1.269,1	100,4
Диңгез флоты халык комиссариаты	119,2	143,8	120,0
Елга флоты халык комиссариаты	207,9	249,8	120,1
Элемтә халык комиссариаты	229,7	263,0	114,5
СССР сәламәтлек саклау халык комиссариаты	267,2	311,3	116,5
СССР финанс халык комиссариаты	178,9	188,4	105,3
СССР Совнаркомы янындагы кинематография эшләре комитеты	299,8	354,7	118,3
РЕСПУБЛИКА ПРОМЫШЛЕННОСТЬ НАРКОМАТЛАРЫ:			
Союзный республикаларның җирле промышленность наркоматлары	2.412,5	2.702,7	112,0
Союзный республикаларның җирле ягулык промышленносты наркоматлары	270,3	293,1	108,4
II.			
Промысло кооперациясе продукциясе (1932 нче елгы бәяләрдә миллион сум белән)	15.025,5	18.177,3	121,0
Шул исәптән:			
Всекопромсовет	12.002,1	14.652,8	122,1
Всекопромлессоюз	1.563,0	1.779,0	113,8
Инвалидлар кооперациясе	1.460,4	1.745,5	119,5
III.			
Тимер юлларда барлык йөкләрне тәүлектә уртача төяү (шартлы ике күчәрле вагоннар белән)	88.046	93.374	106
IV.			
Ваклап сату товар әйләнеше, җәмагат тукландуын да кертеп (миллион сумнарда)	140.020	163.456	116,7

1939 нчы елны барлык наркоматларда промышленность продукциясе эшләп чыгаруны 1938 нче елга чагыштырганда арттырдылар.

СССР Совнаркомы янындагы Дәүләт План Комиссиясе.



„Спартак“ комбинаты порусин аяк киемнәре цехында үкчәләрне калыпсыз тарту машинасында эшләүче стахановка Фатыйма Шакирова. Айлык эшләп чыгару нормасын яхшы сыйфат белән үтәп килә һәм яхшы сыйфатлы товар чыгарган өчен өстәмә хак ала. И. Галиев фотосы.

Батыр седовчыларга ялкынлы сәлам!

АРКТИКА БӘҺАДИРЛАРЫНА

Кадерле седовчы иптәшләр!

Москва Хәрби Округы гаскәрләре, бөтен совет халкы белән берлектә, Сезнең гүзәл фәнни эшегезне гаять зур игтибар белән күзәттеләр.

Сез Арктиканың мәңгелек бозларына һәм каты бураннарына каршы көрәштә геройлык һәм батырлык күрсәттегез.

Сезнең батырлыкларыгыз Москва Хәрби Округы сугышчыларын, командирларын, комиссарларын һәм политработникларын хәрби һәм политик хәзерлектә яңа уңышлар яулап алуга рухландыралар.

Кулларыгызны нык кысабыз һәм Зур Җиргә кайтуыгызны түземсезлек белән көтәбез.

Москва Хәрби Округының
Хәрби Советы:
С. Буденный.
А. Щербаков.
А. Запорожец.
А. Лобачев.

„СЕДОВ“ БОЗВАТКЫЧЫ КАПИТАНЫ ИПТӘШ БАДИГИНГА

Сезне һәм бозваткычның бөтен личный составын героик хәрәкәтнең уңышлы төгәлләнүе белән котлыйм. Туган яр буйларына уңышлы рәвештә кайтып җитүегезне телим.

Н. Кузнецов.
Хәрби Диңгез Флоты Халык Комиссары.

БАТЫР СЕДОВЧЫЛАРГА ДАН!

Яңа котып эпопеясе тәмам булды. Бөтен совет халкы седовчыларга кул чаба. Аларга карата безнең мәхәббәтебез бөек һәм чиксез. Седовчылар үзләренә йөкләтелгән авыр бурычны намус белән үтәделәр, совет фәненә яңа тиңдәшсез хәзинә керттеләр. Мондый героик эшләр бары тик безнең социализм илендә генә мөмкин.

Совет кешеләре партиянең һәм хөкүмәтнең теләсә нинди заданиеләрен батырлык һәм геройлык белән үтиләр. Моның сәбәбе—совет патриотларының үз Ватаннарына чиксез мәхәббәт күрсәтүләре, коммунизм тантанасына чын күңелдән ышанулары, большевистик партиягә һәм халыкларның юлбашчысы иптәш Сталинга чын күңелдән бирелгәнлекләре.

Батыр седовчыларга дан!

И. И. Гудов.
СССР Верховный Советы депутаты.

СОВЕТ ХАЛКЫ ГЕРОЙ СЕДОВЧЫЛАРНЫ КОТЛЫЙ

„Седов“ бозваткычындагы 15 котыпчы морякның хәрәкәттәге карабтагы героик экспедициясе тәмам булуга бөтен совет халкы шатлана һәм куана. Күп санлы хатларда, телеграммаларда һәм митингларда хезмәт ияләре батыр седовчыларны кайнар рәвештә котлыйлар.

Москвадагы „Красный Пролетарий“ заводының барлык сменаларында митинглар булды. Эшчеләр, инженерлар һәм хезмәткәрләр герой седовчыларга котлауларында болай язалар:

„Совет халкы белән нык бәйләнештә булган һәм даими рәвештә партия, хөкүмәт һәм Сталин тарафыннан кайгыртучанлык сизеп эшләгән седовчылар коллективы табигать белән көрәштә җиңүче булып чыкты. Ул гына да түгел, ул зур күләмдә фәнни эш алып барды һәм Арктиканың күп серләрен ачты.

Без, краснопролетарчылар, седовчыларның героик коллективын кайнар рәвештә котлап, Ватаныбызның кыю улларыннан авырлыкларны большевикларча ничек җиңәргә өйрәнербез“.

Москваның „Калибр“ заводындагы тантаналы митингка 2 меңгә якын кеше җыелды. Кабул ителгән резолюциядә завод коллективы түбәндәгечә белдерә:

„Тарихта үрнәге булмаган батырлыклар күрсәткән героик совет котыпчыларына, барлык совет халкы белән берлектә, кайнар котлавыбызны җибәрәбез.

Без, бу батырлык үрнәге белән рухланган хәлдә, үзебезнең Ватаныбызның һәм җиңелмәс Кызыл Армиябезнең куәтен стахановча бердәм эшләү белән тагын да ныгытырбыз.

„Яшәсен Ватаныбызның сөекле уллары—седовчылар!“.

Ворошиловград предприятиеләрендә „Седов“ бозваткычының героик хәрәкәтне төгәлләвенә багышланган зур митинглар бара. Октябрь Революциясе исемендәге заводның паровозлар цехында җыелган митингта 1.500 кеше катнашты.

Митингта катнашучылар седовчыларга түбәндәгечә котлау белән мөраҗәгать иттеләр. „Сталин батырларына—„Седов“ экипажына, шулай ук Арктика флотының флагманы „И. Сталин“ бозваткычының личный составына, аларның батырлыклары уңае белән, үзебезнең кайнар мәхәббәтебезне һәм соклануыбызны белдерәбез. Безнең алдынгы совет фәненең уңышларын арттыручы бөек совет халкының батыр улларына кайнар сәлам җибәрәбез“.

Арктиканың сөекле геройларын—седовчыларны, шулай ук, Вольскийның (Саратов өлкәсе) „Красный Октябрь“ цемент заводы коллективы, Украина ССР Фәннәр Академиясе президиумы, Украина совет художниклары союзы, СССР Диңгез Флоты Халык Комиссариатының Ростов диңгез техникумы укучылары һәм укытучылары, Советлар Союзы Герое комбриг Туржанский, өлкән лейтенант Семенов һәм өлкән политрук Бамбуров, СССР ның халык артисты Самосуд, орденлы язучы Панферов, академиклардан—Бернадский һәм Архангельский, Кара диңгез сәүдә флотының орденлы моряклары—Петров, Мезенцев, Макаренко һәм башка бик күпләр кайнар рәвештә котлыйлар.

(ТАСС).

Седовчыларның җиңүе—барлык совет кешеләре өчен үрнәк

МУРМАНСКИЙ, 14 гыйнвар. (ТАСС ның махсус хәбәрчесе). „Г. Седов“ бозваткычының тиңдәшсез хәрәкәте гүзәл рәвештә тәмам булу турындагы шатлыклы хәбәр бөтен шәһәргә яшен тизлеге белән таралып өлгерде. Седовчы матрос Ефим Гаманковның хатыны Мария Андреевна Гаманкова һәм седовчы гүзәл радист Александр Александрович Полянскийның туганы механик Николай Полянский янына уннарча дуслары, танышлары, күршеләре керәләр. Аларның кулларын чын күңелдән кысалар, аларны туганнары белән тиздән булачак очрашу белән котлыйлар.

Мария Андреевна Гаманкова болай ди:

— Мин седовчыларның җиңәчәген белдем. Сталин заданиесен аларның намус белән үтәячәкләрен белдем.

— Седовчылар үзләренең хәрәкәтләренең икенче еллыгында ук инде хәрәкәтне уңышлы төгәлләү өчен барлык көчләрен кую турында иптәш Сталинга вагдә бирделәр. Алар тагын шуның өчен җиңделәр, чөнки аларның коллективы Ватанга, партиягә, бөек Сталинга чын күңелдән бирелгәнлек белән нык тупланган иде.

Портта, сәүдә порты пароходларында, Лаптевлар диңгезе бозлары арасында „Седов“ белән берлектә кышлаган „Садко“ бозваткычында, Мурманрыба предприятиеләрендә, диңгез техникумында, судоверфьта, бозлар арасында патрульлек хезмәтен үтәгән „Мурманец“ бортында булган зур митингларда сөйләүчеләр, Арктиканың иң кыен участкыларында 26 ай буена фәнни вахта алып барган котыпчыларның батырлыклары турында сокланып сөйләделәр.

Хезмәт ияләре үзләренең резолюцияләрендә, герой седовчыларны һәм Арктика флотының флагманы „И. Сталин“ экипажын чын күңелдән котлап, седовчыларның гүзәл җиңүләре барлык совет кешеләре өчен үрнәк булып хезмәт итәр, дип белдерәләр.

ЗАДАНИЕНЕҢ ИКЕНЧЕ ӨЛЕШЕН ҮТИ БАШЛАДЫК

„И. Сталин“ бозваткычы борты, 14 гыйнвар. (ТАСС хәбәрчесеннән радио буенча). Седовчылар белән очрашканнан соң берничә сәгать үткәч, без партия һәм хөкүмәт заданиесенең икенче өлешен үтәргә керештек.

„И. Сталин“ бозваткычыннан „Седов“ командасы составына 21 кеше бирелде.

Безнең механиклар седовчылар белән бергә „Седов“ карабының механизмнарын һәм корпусларын карап чыктылар. Хәзерге вакытта карабның винтларын һәм рулен боздан чистартабыз. Бүгенге көндә безнең барыбыз өчен дә төп бурыч—пароходны үзе ябышып каткан боздан арындыру. „Седов“ка ябышып каткан бозның калынлыгы 4—5 метр. Бортлардан боз кырыйена кадәр 3—4 метр. Судно корпусының су асты өлешен боздан арындыру—техник яктан катлаулы эш. Ул күп вакыт алачак.

Карабның руль хуҗалыгы да зур гына кайгыртучанлык күрсәтүне таләп итә. Без рульнең эшләве өчен бар нәрсәне дә эшләргә тырышабыз, диярга кирәк, шулай да, ихтимал, безгә „Седов“ны буксирга тагып алып китәргә туры килер. Водолазларыбыздан „Седов“ның су асты өлешен карату өчен Баренцбургка керү мөмкинлеге дә юк түгел.

Бүген без „Седов“ ка күмер, азык, эчә торган су—шулай ук азыклардан яңа фруктылар: мандарин, алма, груша төяү эшен төгәлләрбез.

Безнең кинога төшерә торган группабыз караб эчендә эшли, аның барлык биналарын төшерә.

Седовчылар „Мылтыклы кеше“ дигән кинофильмне зур игтибар һәм кызыксыну белән карадылар.

И. Папанин.

СОВЕТ ХАЛКЫ УЛЫ

Социалистик Ватанның батыр унбиш улы ике елдан да артыграк вакыт эчендә, авыр шартларда, әлегәчә өйрәнелмәгән, үлем куркынычы белән тулы булган котып бассейнын өйрәнделәр. Седовчылар кешенең табигатне җиңүе тарихына тагын бер данлыклы сәхифәне яздылар.

Советлар союзы Арктиканы тикшерү, өйрәнү һәм үзләштерү буенча кешелек дөньясы тарихында әлегә кадәр һичбер күрелмәгән эшне җәелдерде. Героик дүрт папанинчы тарафыннан үткәрелгән бу эшнең йомгаклары хәтердә бүгенгедәй саклана. Моның артыннан Сталин лачыннары Чкалов һәм Громов кызыл канатлы корыч кошларда Төньяк Котып аркылы очып үттеләр. Хәзер ил Арктиканы буйсындыручы яңа геройларны—седовчыларны тантаналы рәвештә хөрмәтләүгә хәзерләнә. Седовчылар героик совет халкын, аның салкын канлылыгын, куркусызлыгын һәм батырлыгын гәүдәләндерәләр. Үзенең ялгыз гына булмавын, аны сөекле Ватан, куәтле совет халкы, большевиклар партиясе, бөек Сталин күзәтеп торганлыкны белеп, героик экипаж барлык киртәләрне җиңде. Бу—седовчыларны энергия һәм батырлык белән коралландырды, аларны рәхимсез Арктиканы тулы җиңүгә алып барды.

Батыр седовчыларга ялкынлы сәлам!

А. Г. Стаханов.

БАТЫРЛЫК ҮРНӘГЕ

Авыл хуҗалыгы фәннәренең В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз Академиясе „Седов“ ның данлыклы экипажын, Арктика турындагы фәнгә кыйммәтле хәзинә булган эшне уңышлы үтәве белән котлый.

Седовчылар коллективы батырлык һәм Ватанга чын күңелдән бирелгәнлек үрнәге күрсәтте. Героик экипажның җиңүләре белән бөтен совет халкы горурлана.

Батыр совет патриотларының—седовчыларның Зур Җиргә кайтуларын түземсезлек белән көтәбез.

Академиклар: *Т. Д. Лысенко, Н. В. Цицин, В. П. Мосолов, М. С. Сиваченко, К. И. Скрябин, Б. А. Келер, Е. Ф. Лескун, И. В. Якушкин.*

МОСКВА СЕДОВЧЫЛАРНЫ КАРШЫ АЛЫРГА ХӘЗЕРЛӘНӘ

„Седов“ бозваткычының героик хәрәкәте тәмам булу турындагы хәбәрне Кызыл башкаланың хезмәт ияләре гаять зур шатлык белән каршы алдылар. Москваның клубларында, театрларында, культура йортларында, мәктәпләрендә һәм предприятиеләрендә седовчылар турында лекцияләр, данлыклы котыпчыларга багышланган күргәзмәләр, концертлар һәм кичәләр оештырыла. (ТАСС).

СЕДОВЧЫЛАРНЫҢ ГЕРОИК ЭШ КӨННӘРЕ

В. КОНОНОВ

Төньяк Диңгез Юлы работниклары профсоюзы Үзәк Комитеты председателе

Советның батыр 15 котыпчысы—„Седов“ бозваткычы экипажы—үз-үзен аямаучан эше белән большевистик ныклыкны, батырлыкны һәм гайрәтлелекне бер нинди дә кыенлыклар җимерә алмаганлыгын бөтен дөньяга күрсәтте. Хәрәкәт итүче карабның экипажы — дус, бердәм коллектив. Седовчылар большевистик оешканлык, дисциплиналылык, сизгерлек, эшкә социалистик караш үрнәге булып хезмәт итә алалар.

Советның данлыклы 15 патриоты, туган ил ярларыннан еракта булып, тулы иҗади тормыш белән яшәде.

Бөек Октябрь Социалистик Революциясенең XXI нче еллыгы алдыннан илдә Октябрь алды социалистик ярышы киң җәелә. Седовчыларның бердәм коллективы котыпчылар арасында беренче булып бу ярышка кушылды. Ул Төньяк Диңгез Юлы предприятиеләре эшенең барлык тармакларында комплекслы ярышның инициаторы булды. „Седов“ экипажы, меңнәрчә совет котыпчыларын үз артыннан ияртеп, өстенә алган йөкләмәләрне намус белән үтәде. Чын социалистик хезмәт үрнәкләре өчен седовчыларның барсы да Төньяк Диңгез Юлы Баш Идарәсе җитәкчелеге тарафыннан „Почетлы котыпчы“ значогы белән бүләкләнделәр.

Хезмәт көнен тәмам итү белән седовчылар кают-кампаниягә җыйналалар. Биредә алар укыйлар, аларның буш вакытлары шунда үтә. Седовчылар ВКП(б) тарихын гаять зур кызыксыну белән өйрәнәләр. Үткән елны „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ның бүлекләре Диксон атавыннан седовчылар өчен радио аша тәртипле рәвештә тапшырылды. Героик экспедициядә катнашучылар конспектларны игтибар белән төзеделәр. Бадигин, Трофимов, Буйницкий иптәшләр һәм башка седовчылар марксизм ленинизм классикларының—Маркс, Энгельс, Ленин—Сталинның әсәрләрен үзлекләреннән өйрәнделәр.

„Седов“ кешеләре үзләренең квалификацияләрен күтәрүгә күп игтибар бирделәр. Алар алгебраны, физиканы, электротехниканы һәм башкаларны өйрәнделәр. Бу занятиеләргә капитан Бадигин, помполит Трофимов, капитанның өлкән ярдәмчесе Ефремов, гидрограф Буйницкий һәм врач Соболевский җитәкчелек иттеләр.

Ике меңнән артык китабы булган судно көтепханәсе котыпчылар арасында зур почетлы урынны тота. Диңгездә йөрү, техника мәсьәләләре, җәмагать-политик мәсьәләләр турындагы әдәбият көтепханәдән файдаланучыларга хезмәт күрсәтә. Матур әдәбияттан аеруча сайланма төрле китаплар бар. Көтепханәдә Пушкин, Гоголь, Лермонтов, Горький, Салтыков-Щедрин, Гюго һәм башка күп язучыларның әсәрләре бар. Көтепханәче хезмәтен башкаручы машинист Шәрыпов, китапка сорау бик зур булганлыктан, көчкә генә өлгерә ала.

„Седов“ның үзендә кино-театр бар. Команда карамагында тавышлы кино аппарат һәм уннан артык фильм бар.

Седовчылар буш вакытларында „Без җиңәрбез“ дигән стена газетасын чыгаралар. Газета тәртипле рәвештә чыга. Седовчылар Зур Җиргә әйләнеп кайтканга кадәр аны чыгаруны туктатмаска булдылар.

Героик карабның командасы, шартларның кыен булуына да карамастан, хәрби белемнәрне тәртипле рәвештә үзләштерде, физкультура белән шөгылләнде. Седовчылар чаңгыларда йөрделәр, атарга, санитария эшенә өйрәнделәр.

Үткән ел седовчылар белән Челюскин мысының котып станциясе работниклары арасында читтән торып шахмат турниры үткәрелде. Ул челюскинчыларның җиңүе белән тәмам булды. Бу—седовчыларның бөтен хәрәкәт вакыты эчендә беренче һәм бердәнбер җиңелүләре булды.

Бөтен хәрәкәт вактында героик котыпчыларның семьяләре партиянең, хөкүмәтнең, бөтен совет халкының көндәлек кайгыртучанлыгы һәм игтибары белән чолгап алындылар. Алар өчен системалы рәвештә радио тапшырулар оештырылды. Профсоюз оешмалары седовчыларның туганнарына санаторияларга һәм ял йортларына путевкалар бирделәр. Батыр котыпчыларның балалары җәй көннәрендә пионерлар лагерларында һәм санаторияларда ял иттеләр.

Бөек совет халкы үзенең Ватанга җиңүчеләр булып әйләнеп кайтучы улларын тиздән шатлык белән каршы алыр.

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

БРЮССЕЛЬ, 14 гыйнвар. (ТАСС). Бельга агентлыгының Люксембургтан хәбәр итүенә караганда, „12 нче гыйнварда Люксембургта Франция артиллериясенең ату тавышлары яхшы ишетелеп торган. Халык нык рәвештә куркынган, чөнки снарядлар халык тора торган пунктлар тирәсенә төшкәннәр. Люксембург территориясенә төшкән снарядлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән чокырларның диаметры 2 метрга якын булган. Бу юлы зур калибрлы артиллерия хәрәкәт иткән булса кирәк.

ПАРИЖ, 14 гыйнвар. (ТАСС). Франциянең рәсми белдерүендә, кичә кич белән Блис елгасы белән Рейн арасындагы фронтның барлык участкыларында артиллерия атышы булганлыгы күрсәтелә. Шулай ук һәр ике якның авиациясе актив рәвештә хәрәкәт иткән.

Бүген иртә белән чыгарылган белдерүдә: „Төн тыныч үтте. Кичә Франция линияләре дошман самолетын бәреп төшерделәр“ диелә.

БОЛГАРИЯ ЭКОНОМИК ДАИРӘЛӘРЕНЕҢ КИҢӘШМӘСЕ

ПАРИЖ, 14 гыйнвар. (ТАСС). Гавас агентлыгы Софиядән түбәндәге белдерүне тапшыра: „Болгария финанс министрлегендә киңәшмә булды. Киңәшмәдә финанс һәм сәүдә министрләре һәм Болгариянең мамык промышленносты вәкилләре булдылар. Утырышта Болгария—Совет сәүдә договоры өйрәнелде. Күптән түгел генә кул куелган бу договор Болгария фабрикаларында Советлар Союзы фабрикалары өчен рус мамыгыннан җеп эрләүне күздә тота.

Финанс министре, бу операциянең 40 мең болгар эшчесенә эш бирәчәген һәм хезмәт хакы фондын шактый үстерүне тәэмин итәчәген белдерде.

Шул договорның кайбер детальләрен рәткә салу өчен Болгариянең мамык-җеп промышленносты вәкилләре шушы көннәрдә Москвага чыгып китәләр.

АБӘ КАБИНЕТЫ ОТСТАВКАГА ЧЫКТЫ

ТОКИО, 14 гыйнвар. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгы, бүген, кабинетның гадәттән тыш утырышыннан соң, премьер Абәның император сараенда булганлыгын һәм бөтен кабинет белән берлектә отставкага чыкканлыгын хәбәр итә. Отставка император тарафыннан кабул ителгән.

Яңа кабинет төзүне император югары хәрби совет члены адмирал Ионай Мицумасага тапшырган.

АБӘНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ТОКИО, 14 гыйнвар. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгы радио буенча, бүген, кабинет отставкага чыкканнан соң, премьер Абәның түбәндәге белдерүне ясаганлыгын хәбәр итә: „Узган елның августыннан бирле, император миңа кабинет төзүне тапшырган вакыттан алып, мин һәм кабинет буенча минем коллегаларым эчке һәм тышкы политик мәсьәләләрне һәм бигрәк тә Кытай мәсьәләсен бергәләп хәл итүгә омтылдык. Ләкин кабул ителгән политика линиясен үткәргән вакытта, дәүләт эшләрен алып бару юлларына карата фикер каршылыклары килеп чыгар, дигән куркулар барлыкка килде. Шул уңай белән мин бүген императорга кабинетның отставкасы турында үтенеч тапшырдым. Дәүләт эшләрен үтәүдә мөмкин булган тоткарлыкны һәм Кытай мәсьәләсен хәл итүгә аның файдасыз йогынтысын бетерү теләге белән бу отставка тизләтелде“.

ВАН ЦЗИН-ВЕЙ ЛАГЕРЫНДА РАСКОЛ

ШАНХАЙ, 14 гыйнвар. (ТАСС). „Чайна Пресс“ газетасы бүген, ванцзинвейчеләр арасында раскол турындагы хәбәрләрнең тулысынча расланганлыгын хәбәр итә. Газета, Ван Цзин-вей группировкасының күренекле өч эшлеклесе, шул исәптән Чен Гун-бо, Ван Цзин-вейдән аерылдылар, дип күрсәтә. Хәбәрдар даирәләрнең мәгълүматларына караганда, Чен Гун-бо 31 нче декабрьдә Шанхайдан Гонконгка чыгып киткән. Ван Цзин-вейдән аерылган башка ике эшлекленең берсе—Гао Цзун-у, чит ил эшләре министрлегенең Азия эшләре бюросының элекке директоры, икенчесе—Дао Си-синь, гоминданның үзәк политик советының элекке члены.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясендә, Наньниннан көньяк-көнчыгышка таба, япон гаскәрләре 10 нчы гыйнварда кытайларны уңышсыз рәвештә Налян тирәсендәге позицияләреннән кысрыкларга маташтылар. Кытайлар көтелмәгәндә ясалган атака белән японнарның флангысына көчле контрудар ясадылар. Японнар зур югалтулар ясарга мәҗбүр булдылар. Гуйлиньгуань дигән тау аралыгы өчен булган сугышларда япон частьләре полковник Мики командасында күп кенә офицерларын югалтканнар. 21 офицер үтерелгән һәм 16 офицер яраланган. 12 нче гыйнварда кытай гаскәрләре Наньниннан төньяк-көнчыгышка таба берничә километрда японнарның механикалаштырылган отрядларының базаларына атака ясадылар. Бу атака вакытында японнарның берничә йөк автомобиле һәм танклары юкка чыгарылды.

Гуандун провинциясендә кытай гаскәрләре 13 нче гыйнварда өч юнәлеш буйлап һөҗүмне дәвам иттерделәр.

Кытай ягыннан алынган мәгълүматларга караганда, Кантоннан төньяк-көнчыгышка таба булган сугышларда соңгы ике көн эчендә 3 меңгә якын япон солдаты һәм офицеры үтерелгән һәм яраланган.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Цзянси провинциясенең төньяк өлешендә кытай гаскәрләре Дэаньга атака ясадылар. Шәһәрнең көнбатыш бистәләрендә сугышлар бара. Кытайлар бер үк вакытта Дэаньнан көньякка таба 20 километрда япон гаскәрләренең позицияләренә атака ясадылар.

Хубэй провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә кытай гаскәрләре Тунчен районында һөҗүмне яңарттылар. 3 көнлек сугыш нәтиҗәсендә японнар кайбер урыннарда төньякка таба чигенделәр.

Хубэй провинциясенең төньяк өлешендә Суйчжоу секторында кытайлар 12 нче гыйнварда, японнарның отрядын җимереп, 3 авылны алдылар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгышында Чжанцзы районында кытай гаскәрләре һөҗүмне дәвам иттереп, берничә авылны кире алдылар. Кытайларның авангард отряды Чжанцзыга якын ук килде. Шәһәрнең төньяк бистәләрендә сугышлар бара. Японнарның Чжанцзыга чигенгән бер отряды кытайлар тарафыннан әйләндереп алынды һәм бетерелде. Провинциянең көньяк өлешендә кытай гаскәрләре Сясяньгә атакалар алып баруны дәвам иттерәләр.

14 гыйнвар. (ТАСС).

Англия заводында забастовка

ЛОНДОН, 11 гыйнвар. (ТАСС). „Дейли Уоркер“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Саутпортта (Ланкашир графлыгы) Брокхаузның металлургия заводында 200 эшченең забастовкасы инде 6 көн дәвам итә. Забастовка профсоюзның цех уполномоченныен администрациянең эштән азат итүе уңае белән башланган. Забастовкачылар аны үз эшенә кире кайтаруны таләп итәләр.

Франциядә кулга алулар

НЬЮ-ЙОРК, 12 гыйнвар. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Лилльдә (Франция) полиция квартирага налет ясаган һәм компартиядә торуда гаепләп 8 кешене кулга алган.

НОРВЕГИЯ ЯЗУЧЫСЫ ГРИГ СУГЫШ УТЫ КАБЫЗУЧЫЛАРГА КАРШЫ

СТОКГОЛЬМ, 13 гыйнвар. (ТАСС). Норвегиянең атаклы язучысы Нордаль Григ армиягә алынды һәм хәзер Норвегиянең төньягында, Финмаркенда тора. Соңгы вакытта буржуаз газеталар, язучының Советлар Союзына карата мәхәббәт күрсәтүеннән баш тартуын таләп итеп, аны һәр төрле юллар белән мәсхәрәләп килделәр. Кичә „Дагбладет“ газетасында Григ: „Минем фикерләрем кем белән?“ дигән җавап мәкаләсе белән чыкты.

Григ болай яза:

„Декабрь аенда күп кенә газеталар, минем политик карашларымны белдерүемне таләп итеп, минем адреска карата мәсхәрәләү мәкаләләре иглан иттеләр. Мин хезмәт итә торган частьтә гаять каты цензура урнаштырылган, биредән хатлар һәм телеграммалар җибәрү тыелган. Шушындый хәлдә миңа һөҗүм итү иң аз дигәндә әдәпсезлек икәнлекне һәр кем аңларга тиеш. Мин үз өемдә түгел һәм минем үз фикерләремне иркле рәвештә белдерү мөмкинлегем юк.

Мин кыска тотам. Минем өметләрем бүген, һәр вакыттагы шикелле үк, буржуаз язучыларның омтылышларыннан үзгә буларак, үземнең Норвегиям белән, Норвегиянең тынычлык теләүче һәм сугышны дошман күрүче хезмәт халкы белән бәйләнгән. Капиталистлар, сәүдәгәрләр һәм башка эксплуататорлар Норвегия халкын канлы суешка кертергә омтылалар. Мин, илне нейтралитет хәленнән тартып чыгарырга маташучы кешеләр Норвегиянең бердән-бер дошманнары булып торалар, дип белдерәм“.

Төркиядә җир тетрәүнең нәтиҗәләре

ӘНКАРА, 14 гыйнвар. (ТАСС). Төркиянең эчке эшләр министре Фаик Оэтрак мәҗлес утырышында Көнчыгыш Анатолиядә җир тетрәүнең нәтиҗәләре турында белдерү белән чыкты. Хөкүмәтнең рәсми мәгълүматларына караганда, һәлак булучылар саны 23 мең кешегә җитә, ә яраланганнар саны—8 мең. Шуннан тыш, 29 мең йорт җимерелгән.

Җир тетрәү булган районнарда җимерелгән йортлардан калган материаллардан бараклар төзү эше бара. Җимерелгән Эрзинҗан шәһәре урнында хөкүмәт яңа шәһәр салырга карар бирде.

Япониянең яшрен советы балык тоту турында СССР белән Япония арасында төзелгән килешүне яхшы дип тапты

ТОКИО, 14 гыйнвар. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 13 нче гыйнварда яшрен совет утырышында, император алдында, Совет—Япония килешүе яхшы дип табылган. Бу килешү 31 нче декабрьдә СССР белән Япония арасында 1928 нче елда төзелгән конвенцияне 1940 нчы елга озайту турында төзелгән иде.

Бауман районы 11 нче номерлы урта мәктәпнең кызыл байраклы 6 нчы „А“ классы каникулдан соң дәрестә. РӘСЕМДӘ: класс җитәкчесе һәм немец теле укытучысы иптәш Н. Ферсова дәрес вактында. И. Галиев фотосы.

ЛЕНИН КӨННӘРЕ АЛДЫННАН

В. И. ЛЕНИН ҮЗӘК МУЗЕЕНДӘ

В. И. Ленин Үзәк Музее Советлар Союзының хезмәт ияләре арасында гаять зур популярлек белән файдалана. Бирегә меңләгән москвалылар һәм экскурсиячеләр көн саен В. И. Лениннең һәм Ленин эшен дәвам иттерүче бөек Сталинның тормышларында һәм эшләрендә булган иң мөһим моментларны чагылдырган экспонатлар белән танышалар. Музей ачылганнан—1936 нчы елның 15 нче маеннан бирле анда 4.250.000 нән артык кеше булды. Бер үткән ел эчендә генә дә музейнең экспонатлары белән миллионнан артык кеше танышты. Бирегә безнең илебезнең барлык почмакларыннан да экскурсиячеләр килделәр. Музейдә шулай ук чит ил хезмәт ияләре делегацияләре дә булдылар.

Хәзер Ленин көннәре якынлашу уңае белән музейгә килүчеләрнең саны нык дәрәҗәдә үсте. Экскурсияләр оештыру турында төрле оешмалардан күп санда заявкалар алына. 12 нче гыйнварда музейдә 5 меңгә якын кеше булды. Аның якты һәм иркен залларында эшчеләрне, колхозчыларны, хезмәткәрләрне, лекторларны һәм агитаторларны очратырга мөмкин иде. Кызыл Армия сугышчылары, командирлары һәм политработниклары аеруча күп иде.

Музейгә өзлексез рәвештә документлар өстәлеп тора. В. И. Ленин үлүгә 16 ел тулу уңае белән залларга күп кенә яңа экспонатлар куелды.

В. И. Лениннең эш кабинеты белән янәшә булган XIII нче залга Владимир Ильичның эш көнен характерлый торган экспонатлар җыелды. Күп сандагы документлар бюрократизмга, волокитага һәм взяткачылыкка каршы Лениннең көрәшен, кешеләр турында кайгыртуын күрсәтәләр. Бирегә Владимир Ильичның партия документлары һәм шәхси әйберләре куелган. Шулай ук Совет власты яшәвенең беренче көннәреннән үк фәнне, культураны, техниканы үстерүгә Лениннең никадәр зур әһәмият бирүен күрсәткән документлар да куела. Бу залга куелган 25 яңа экспонат арасында Ленин кулъязмаларыннан алынган фото-рәсемнәр бар.

В. И. Лениннең „Петроградта халык китепханәсенең бурычлары турында“ дигән кульязмасыннан (1917 нче елның ноябре) алынган фото-күчермә аеруча зур кызыксыну тудыра. Ул болай дип башлана:

„Революциядә акыл белән, уйлап һәм уңышлы катнашу өчен укырга кирәк“.

В. И. Ленин тарафыннан 1921 нче елның 28 нче февралендә Н. А. Симашкога крестьян Чекунов өчен күзлек сорап язылган хат, шулай ук В. И. Лениннең 1921 нче елның 19 нчы сентябрендә лифт эше турында язган хаты бөек Лениннең кешеләр турында кайгыртуын ачык күрсәтәләр. Хатта болай диелә:

„Миңа 20, 21 һәм 22 нче сентябрьдә лифтның эшләмәячәге турында белдерделәр.

Бу иң зур кабахәтлек. Йөрәк авырулы кешеләр бар, аларга югарыга күтәрелү зарарлы һәм куркыныч. Мин җаваплы кеше билгеләп, лифтны күзәтергә мең тапкыр тапшырган идем инде“.

Документлар арасында В. И. Лениннең 1920 нче елның 15 нче сентябрендә Черемхово күмер казучыларына язган хаты бар. Бу хатта Владимир Ильич түбәндәгечә яза:

„Совет властының алпавытларны, капиталистларны һәм һәр төрле эксплуататорларны тулысынча һәм тәмам җиңүенә иң тирән ышану хисләре, шулай ук барлык комачаулыкларны һәм кыенлыкларны җиңүгә карата какшамас ныклык һәм карарчанлык—сезнең котлавыгызда, иптәшләр, аеруча кыйммәтле булып торалар. Эшчеләрнең, хезмәт ияләре массасының нак менә шушы ныклыгыннан һәрбер коммунист кебек үк мин дә эшчеләрнең һәм эшчеләр эшенең бөтен дөнья күләмендә котылгысыз рәвештә җиңүенә ышаныч алам“.

Шушы ук залда В. И. Лениннең шәхси әйберләре арасында аның кул сәгате һәм буркасы куелган. Якын көннәрдә залга тагын күп кенә фото-рәсемнәр куелачак.

Музейгә килүчеләр беренче тапкыр буларак В. И. Лениннең 1922 нче елны Горькида алынган һәм XVI нчы залга куелган фото-рәсмен күрәчәкләр.

(ТАСС).

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ РАБОТНИКЛАРЫ ӨЧЕН КИЧКЕ УНИВЕРСИТЕТ

Авыл хуҗалыгы белгечләренең белемнәрен күтәрү буенча кичке университет эшкә башлый. Агрономнар, ветврачлар һәм зоотехниклар монда авыл хуҗалыгының иң яңа проблемалары буенча регуләр рәвештә лекцияләр тыңлаячаклар.

Казан авыл хуҗалыгы институты профессоры ип. П. М. Тихонов „Дарвинизм — селекциянең һәм орлыкчылыкның нигезе“ дигән беренче лекцияне укыячак. Лекцияләрне уку өчен Казан шәһәрендәге фәнни работниклар белән берлектә, авыл хуҗалыгында эшләүче стахановчылар һәм белгечләр дә чакырылачак.

(ТатТАСС).

Терлек үрчетү планы арттырып үтәлде

Бондюг районы, Тайма авылы колхозы терлек үрчетү буенча 1939 нчы елгы планны 110 процент үтәде. Колхоз 1939 нчы елда сарык һәм дуңгыз фермаларыннан 18 мең сум доход алды. Кышлау өчен терлекләргә барлык уңайлы шартлар булдырылды.

Х. Сабитов.

САВЫКТЫРУ ЭШЛӘРЕНӘ 75 МЕҢ СУМ

Казан житен комбинаты фабкомы, ял йортларына һәм санаторияләргә путевкалар алу өчен 75 мең сум акча билгеләде. Быел 208 кеше Васильево ял йортында, 76 кеше Татарстан санаторияләрендә, 200 бала пионер лагерларында ял итәчәкләр. Комбинатның күп кенә стахановчылары Кырым, Кавказ һәм башка курортларга җибәреләчәкләр. (ТатТАСС).

ЛУБЯНДА ЯҢА ТӨЗЕЛЕШ

Тәкәнеш районы, Лубян эшчеләр поселкысында яхшы итеп җиһазландырылган аптека һәм бала тудыру йорты төзелеп, эксплуатациягә бирелде. Бала тудыру йорты бер юлы 20 анага хезмәт күрсәтә алачак. 50 балалык ясле бинасы төзү башланды. (ТатТАСС).

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

КАЗАН ПРОМЫШЛЕННЫЙ БАНК ТЕХНИКУМЫ
1 нче КУРСКА УКУЧЫЛАР АЛА
Техникум төзелешләргә акча җибәрү һәм контрольлек итү эшләре буенча кредит
— инспекторлары хәзерли —
УКУ СРОГЫ—3 ел.
Техникумга 15 тән 30 га кадәр яшьтә булган һәм тулы булмаган урта (7 еллык) мәктәпне тәгәлләгән барлык гражданнар алыналар.
Техникумга керүчеләр шушы ел 20 нче гыйнвардан 1 нче февральгә кадәр, тулы булмаган урта мәктәп программасы күләмендә рус теленнән һәм әдәбиятыннан, математикадан (арифметика, алгебра һәм геометрия), географиядән һәм СССР Конституциясеннән сынаулар үтәләр.
Тулы булмаган урта мәктәпне төп предметлар буенча „отлично“ билгесе белән тәгәлләүчеләр техникумга сынаусыз алыналар. Укулар шушы ел 1 нче февральдә башлана.
Гариза белән бергә, керүченең автобиографиясе, яше һәм тулы булмаган урта мәктәпне тәгәлләү турында документлар, сәламәтлеге турында медицина белешмәсе, һәрберсенә керүченең имзасы куелган һәм дәүләт учреждениесе тарафыннан расланган ике данә фотокарточка бирелергә тиеш.
Гаризалар шушы ел 20 нче гыйнварга кадәр алына.
Техникумга алынганнарга гомуми нигездә стипендия һәм тулай торакта урын бирелә.
Казан, Карл Маркс урамы, 43. Промбанк техникумы. 27—3—3

Барлык гражданнар игтибарына!
ЮВЕЛИРТОРГНЫҢ КАЗАН МАГАЗИНЫ
алтыннан һәм көмештән ясалган ювелир әйберләре, бриллиантлар, башка төрле кыйммәтле ташлар һәм Урал ташлары, энҗеләр, койган һәм кисәкле алтыннар һәм көмешләр, элек сугылган алтын һәм көмеш акчалар, платина, алтын, көмеш һәм металл сәгатьләр (кесә һәм кул сәгатьләр), секундомерлар, хронографлар һәм барлык системадагы сәгать механизмнары
сатып ала
Магазинның адресы: Казан, Бауман урамы, 58. Телефон 11—93. 2—1

КАЗАН ИТ КОМБИНАТЫ
барлык оешмаларның һәм частный кешеләрнең
заказлары буенча
ТЕРЛЕК СУЮ ЭШЛӘРЕ ҮТИ
Суярга билгеләнгән терлекләрне Комбинатка тапшырыгыз. Моның белән, сез, суелган терлекнең итенең һәм тиресенең югары сыйфатлы булуын тәэмин итегез.
Терлек сую, гомуми ял көннәреннән башка, һәр көн эшләнә.
Казан, Тимер юл урамы, 3 (3 нче маршрут трамваеның Холодильник янындагы туктавы). Телефон 33—89. 71—1

„ЗАГОТКОНЬ“
ның Татарстан республика
конторасы
1940 нчы елда атлар бирү буенча дәүләт учреждениеләреннән һәм колхозлардан
ЗАЯВКАЛАР АЛА
һәм алар белән шушы ел 20 нче гыйнварга кадәр
ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ
Бер үк вакытта, „Заготконь“ нәселле атлардан: җиңелгә җигү атлары һәм эш атлары сатып ала. 49—2—2

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Тулысынча яңа программа
Москва 4 нче труппасының
гастрольләре
Бөтен труппа катнаша.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

КИРӘК:
Казан мальтоз-патка заводына (Фуксовский урам, 39. Телефон 8—11) даими эшкә БАШ БУХГАЛТЕР, БУХГАЛТЕР-ФИНАНСИСТ, МАТЕРИАЛЬ БҮЛЕК БУХГАЛТЕРЫ, ХИСАПЧЫ, ТЕПЛОТЕХНИК һәм МАШИНИСТКА. 45—1

С. М. Киров исемендәге Казан Химико-Технология институтына МАШИНИСТКАЛАР, СЛЕСАРЬЛАР, ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР, КОЧЕГАРЛАР һәм ПОДКИДЧИКЛАР, КИЕМ ЭЛГЕЧЕНДӘ ЭШЛӘҮЧЕЛӘР, ҖЫЕШТЫРУЧЫЛАР, автомашиналарда эшләү өчен грузчиклар, ПЫЯЛА КАБАРТУЧЫЛАР, укыту бүлеге өчен СЕКРЕТАРЬ, реактивлар һәм җиһазлар житештерү буенча ИНЖЕНЕР-ХИМИК, ТӘҖРИБӘЛЕ СТЕНОГРАФИСТКА һәм институт китепханәсенең чит телләр бүлегендә эшләү өчен, ЧИТ ТЕЛЛӘРНЕ БЕЛҮЧЕ РАБОТНИК. 35—3—2

Центроэлектромонтажның Казан конторасына, Казанда һәм районнарда эшләү өчен ЭЛЕКТРОСЛЕСАРЬЛАР һәм БАРЛЫК РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР.
Кирәк булса, тулай торакта урын бирелә. Башка шәһәрләрдәге монтаж пунктларына китеп эшләүчеләргә командировка акчасы да бирелә. Казан, Банк урамы, 13. Кадрлар бүлегенә килергә. 30—3—2

Сал агызу институтына һәм Зур Волга бюросына, секторларда эшләү өчен инженерлар, техниклар, конструктор-механиклар, су юлы һәм коры юл белән агач ташу транспорты буенча инженерлар һәм техниклар кирәк. 2570—2—2

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
17 нче гыйнварда
КЫЮ КЫЗЛАР
Талон 97.
Бүген, 16 нчы гыйнварда спектакль булмый.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 16 нчы гыйнварда М. Ю. Лермонтовның тууына 125 ел тулуга багышланган юбилей спектакле
МАСКАРАД
Бүген талон 78.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы художестволы яңа фильм ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	Көндезге сеансларда МИТЬКА ЛЕЛЮК. Кич УКЫТУЧЫ
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	УКЫТУЧЫ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндезге һәм Кичке сеансларда СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	ЦИРК
КУЛЬТУРА САРАЕ 4, 7, 9-30 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (Икенче сериясе)

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 211 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 203.